АТЫҢ КЕМ?

Сәер исем сайлаганда әти-әни бала турында түгел, ә үзләре турында уйлый

> 15

КЫШКЫ АВЫЛ

Сукмакларны кар каплап китмәдеме? Суыкларны ничек җиңәсез? Мал-туарыгыз исән-саумы?

> 16

РЕЗЕДА СӘЛАХОВА:

«Ялтыравыклар белән генә яхшы спектакль чыгарып булмый шул...»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 3 (29163) | Җомга | 12 гыйнвар | 2024 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

depositphotos.com

ИКЕ КАБЫП, БЕР ЙОТУ

АШАУ-ЭЧҮГӘ КИТКӘН ЧЫГЫМНАРНЫ КИМЕТЕП БУЛАМЫ?

Тамактыр – тәмугтыр, ди халык. Хак әйтә. Баксаң, илдә яшәүчеләрнең 60 проценты айлык хезмәт хакының яртысын диярлек азык-төлек кибетендә тотып бетерә икән. Шул ук вакытта Россиядә ел саен 1,6 триллион сумлык ризык чүп чиләгенә оча. Быел кайбер төр азык-төлеккә бәяләр 20 процентка кадәр артырга мөмкин, дип тә кисәтә белгечләр. Ит тештәме, әллә төштәме? Тамак хакы күпме тора? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауларга җавап эзләде.

> 5

Ишетми калмагыз

Хәзерге вакытта Россия Президентын сайлау кампаниясендә 11 кеше катнаша. Үзәк сайлау комиссиясе башлыгы Элла Памфилова әйтүенчә, кандидатларның сигезен сәяси партияләр күрсәткән, ә өчесе үзен үзе тәкъдим иткән.
Үзен үзе тәкъдим итүчеләр – Владимир Путин, Рада Русских һәм Анатолий Баташев. Партияләрдән Леонид Слуцкий (ЛДПР), Владислав Даванков («Новые люди»), Николай Харитонов (КПРФ), Сергей Малинкович («Коммунисты России»), Борис Надеждин («Гражданская инициатива»), Андрей Богданов («Российская партия свободы и справедливости»), Сергей Бабурин («Российский общенародный союз»), Ирина Свиридова («Демократическая партия России») тәкъдим ителгән. Аларның өчесе – Леонид Слуцкий, Владислав Даванков һәм Николай Харитонов кандидат булырак рәсми рәвештә теркәлде инде. Президент сайлау өч көн – 15, 16 һәм 17 мартта узачак.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов быел Казанда БРИКС илләренең Спорт уеннарына әзерләнү һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитетын булдыру турында Указга кул куйды. Оештыру комитетына ул шәхсән үзе җитәкчелек итәчәк. Оештыру комитеты рәисе урынбасарлары: Татарстан вице-премьеры – Министрлар Кабинеты Аппараты җитәкчесе Шамил Гафаров һәм Казан мэры Илсур Метшин.
БРИКС илләре уеннары Казанда 2024 елның июнь уртасында узачак. Анда 50дән артыграк илдән спортчылар катнашуы көтелә. Алар 30 җәйге спорт төре буенча көч сынашачак.

Узган елда Татарстанда 2966 гаилә социаль ипотека буенча торак алган. Дәүләт торак фонды матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, 2023 елда әлеге программа нигезендә республика күләмендә барлыгы 160,7 мең квадрат метр мәйданда 64 йорт төзелгән. Төзелеш зур шәһәрләрдә – Казан һәм Чаллыда аеруча зур колач җәйгән.

Узган елда Татарстанда яңа автомобильләр 4,9 процентка кыйммәтләнгән. «Авто.ру» игъланнар хезмәте мәгълүматларына караганда, тулаем алганда Россиядә яңа машина бәясе уртача 17,3 процентка артып, 3,7 миллион сумга җиткән. Кулланылышта булган машиналар исә 28 процентка кыйммәтләнеп, уртача бәясе 2,2 миллион сумнан арткан. Татарстанда иң нык кыйммәтләнгән яңа машиналар булып «Lada Niva Legend», «Lada Niva», «Chery Tiggo 8 Pro Max» һәм «Chery Tiggo 8 Pro» санала. Кулланылышта булганнары арасында барыннан да бигрәк «Skoda Rapid,» «Kia Rio», «Lada 2107», «Nissan Almera» һәм «Ford Focus»ка бәяләр күтәрелгән.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Узган атнада район балалар хастаханәсенең перинаталь үзәгендә 34 бала дөньяга килгән, шуларның 7се – чит шәһәрнекеләр. Быел районда туган беренче сабыйның авырлыгы – 2060 грамм, буе – 47 см. Ул малай Большаковлар гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килде.
(tat.e-nkama.ru)

Апас

Шәмәк авылында 45 урынга исәпләнгән яңа клуб бинасы ачылды. Республика программасы нигезендә якынча 14 млн сумлык эш башкарылды. 150,6 кв. метр мәйданлы бина үз эченә музей һәм китапханәне дә алган. Клубны төзүдә Шәмәк авылы егете – Россия Дәүләт Думасы депутаты, «Апас» якташлык җәмгыяте президенты Марат Нуриевның зур тырышлыгы салынган. Ул клубка якташлар җәмгыяте исеменнән музыкаль җиһаз тапшырды. Тантанада район башлыгы Айрат Җиһаншин төзүчеләргә Рәхмәт хатлары тапшырды. Мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов авыл халкының гел күтәренке рухта булуын теләп, тальян гармун бүләк итте.
(«Апас-информ»)

Алексеевск

Биләр авылында Россия Герое Рәсим Баксиков хөрмәтенә мактау тактасы ачылды. Аны кайчандыр ул шөгыльләнгән «Юнармеец» яшүсмерләр клубы бинасында урнаштырганнар. «Рәсим Баксиков – Алексеевск районындагы беренче Россия Герое. Биредә яшүсмерләр клубына йөрүче балалар бар, герой тарихы сезнең барыгыз өчен дә тормыш юлында юнәлеш булыр дип өметләнәбез», – диде район башлыгы Сергей Демидов тантанада. Рәсим Баксиков әйтүенчә, хәзерге вакытта махсус хәрби операция зонасында булганнарның барысы да – каһарманнар. «Алар Ватанны саклап, лаеклы көрәшә. Аларга өйләренә исән-сау кайтуларын телим», – диде Рәсим Баксиков.
(«Татар-информ»)

Зәй

30 декабрьдә «Зәй шикәре» заводы узган елгы уңыштан шикәр кайнату сезонын тәгәлләде. Завод бу сезонда барлыгы 725705 мең тонна татлы тамыр эшкәртте, шуның 226 мең тоннасы – Зәй районы кырларыннан китерелгән чимал. «Һава торышы кыр эшләрендә шактый комачаулыклар тудырса да, яңа уңыштан шикәр җитештерү эше өчен чимал җитәрлек булды», – диде завод җитәкчесе Антон Трошин. «Зәй шикәре» заводы бу сезонда 107820 мең тонна шикәр җитештерде, 33513 мең тонна гранулләштырылган жом, 37213 мең тонна меласса әзерләде.
(«Зәй офыклары»)

РОССИЯ МАТБУГАТ КӨНЕ БЕЛӘН!

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИНның Россия матбугат көне уңаеннан котлавы

Хөрмәтле журналистлар, нәширләр, полиграфистлар, блогерлар, ветераннар һәм яшь каләм тибрәтүчеләр, барлык басма һәм цифрлы мәгълүматны әзерләү, бастыру һәм тарату эше белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр! Россия матбугат көнен бәйрәм итү уңаеннан иң ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Ил журналистикасының өч гасырдан артык тарихы хакимият һәм җәмгыятьнең аралашу дәрәҗәсенең, үсешкә омтылышының, милләтара тынычлык һәм граждан татулыгының төрле чорларда күп очракта нәкъ менә массакүләм мәгълүмат чараларының һөнәри осталыгына, аларның һәрьяклап үлчәнгән позициясенә, ватанпәрвәрлек рухына нык бәйле булуын ачык күрсәтә. Бүген дә без массакүләм мәгълүмат чараларыннан булган проблемаларга хакыйкый анализ, иң мөһим көнүзәк мәсьәләләргә җаваплар, объектив һәм битараф булмаган авторлык карашы белән язылган анык мәгълүмат көтәбез.

Яңа гына аяк баскан 2024 ел монын өчен тулы нигез бирә. Россиядә Гаилә елы һәм Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителгән ел зур сайлау циклын ачып җибәрә, әһәмиятле сәяси һәм иҗтимагый вакыйгаларга да ул бай булачак. Март аенда алдагы алты елга сәяси үсешнең юнәлешен билгеләячәк вакыйга – Россия Федерациясе Президентын сайлау узачак. Сентябрьдә татарстанлылар җиденче чакырылыш республика парламенты депутатларын сайлау өчен тавыш бирү участокларына яңадан киләчәк. Быелгы сайлауларның төп үзенчәлеге – махсус хәрби операция чорында Россиягә карата көчле санкция һәм мәгълүмат басымы. Һәм тавыш бирү якынлашкан саен, дус булмаган комментаторларның сайлау кампанияләре һәм, гомумән алганда, илдәге вазгыять хакындагы карашының тискәрелеге көннән-көн артачак. Шушы киеренке вакытта безгә илкүләм лидерыбыз Владимир Владимирович Путин белән тагын да ныграк берләшү бик тә зарур. Без көчле һәм бәйсез Россиянең алга таба да даими үсешенә мөмкин булган ярдәмне, шул исәптән мәгълүмати яктырту белән дә, күрсәтергә тиеш. Безгә Татарстанда узачак халыкара «Киләчәк уеннары», «Россия – Ислам дөньясы» икътисадый форумы, БРИКС дәүләтләре башлыклары саммитын һәм башка чараларны иң югары дәрәҗәдә үткәрергә кирәк. Болар барысы да өстәмә җаваплылык йөкли, ышанам ки, бердәм булып, без аларның бөтенесен дә башкарып чыгарбыз.

ХОКУК САГЫНДА

12 гыйнвар – Россия Федерациясе Прокуратурасы хезмәткәрләре көне. Татарстан Премьер-министры Алексей ПЕСОШИН республика прокуратурасы хезмәткәрләрен һәм ветераннарын һөнәри бәйрәмнәре белән котлады.

«Татарстан Хөкүмәте исеменнән сезне Россия Прокуратурасы хезмәткәрләре көне уңаеннан котлыйм! – диелә котлауда. – Прокуратура инде 300 елдан артыграк вакыт дәвамында Россия гражданнарының хокукын саклау-яклауны тәэмин итүдәге бурычын эзлекле төстә үтәп килә. Бүген прокуратура органнары, Россия дәүләтчелеген, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуда төп рольне уйнавы сәбәпле, илебезнең иң мөһим җәмгыять институтларыннан берсе булып тора. Прокуратура вәкилләренең кырыслыгы, гаделлеге халыкта хокук һәм законның өстенлегенә ышанычны ныгыта. Татарстан Республикасы прокуратура органнарының барлык хезмәткәрләре һәм ветераннарына нык сәламәтлек, бәхет, иминлек, илебез файдасына алга таба эшчәнлектә уңышлар телим».

Спорт

Бу көннәрдә Казан илнең чаңгы үзәгенә әверелде. Башкала читендәге Тынычлык бистәсендә чаңгы ярышлары буенча Россия Кубогының бишенче этабы уза. 11 гыйнварда хатын-кызлар арасында булган беренче ярышта Олимпия чемпионы Вероника Степанова җиңү яулады. Ир-егетләр арасында финишка беренче булып Александр Большунов килде.

ski-tatarstan.ru

ШӘП ШУСЫН!

Өч мәртәбә Олимпия чемпионы Александр Большунов, Савелий Коростелев, Сергей Ардашев, Иван Горбунов, Олимпия чемпионы Вероника Степанова, Мария Истомина, Лидия Горбунова, Дарья Непряева… Исемнәре чаңгы сөючеләргә яхшы таныш әлеге спортчылар бу көннәрдә Казанда ярыша. Татарстан башкаласында Россия Кубогының бишенче этабы уза. Сүз уңаеннан, Александр Большунов белән Вероника Степанова бу сезонда илнең иң көчле чаңгычылары булып санала һәм алар гомуми зачетта беренче урында бара. Димәк, җиңүгә төп дәгъва кылучы да алар.

Кызганыч, Олимпия чемпионнары Юлия Ступак белән Наталья Непряева, Пекин Олимпиадасында ике мәртәбә бронза медальләр откан Александр Терентьев Казанга килә алмадылар. Әмма көндәшлек салкын көнне кыздырырлык дәрәҗәдә булачак. Тынычлык бистәсендәге чаңгы-биатлон комплексы беренче зур ярышны кабул итә. Татарстан спортчылары да үзләрен күрсәтергә тырышачак. Сергей Ардашев – гомуми зачетта икенче урында. Ә хатын-кызлар рейтингында сигезенче һәм тугызынчы урыннарда Лидия Горбунова белән Дарья Непряева урнашкан.

Ярышлар 11 гыйнварда башланды. Беренче көнне спортчылар 10 чакрым арада ирекле стильдә узышты. Хатын-кызлар ярышында финишка беренче булып Вероника Степанованың килүе гаҗәп түгел. «Казандагы трасса миңа ошады. Чөнки җиңдем. Кемнең күпме салат ашаганын белдек. Әмма мин 1 гыйнварда күнегүләр ясый башлаган идем инде. Казандагы барлык ярышларда чыгыш ясарга җыенам», – диде ул. Ә ирләр арасында 15 чакрымны беренче булып, алдан көтелгәнчә, Александр Большунов узды. Бу аның быелгы сезондагы рәттән 13 нче җиңүе! Татарстаннан Иван Горбунов финишка дүртенче булып килде.

13 гыйнварда спортчылар классик стильдә ярышачак. Ә 14 гыйнварда алар скиатлон узышына чыгачак. Ярышларны килеп караган өчен акча түләсе юк. Моннан тыш, чаңгычыларның чыгышын «Матч ТВ» каналыннан да күрергә мөмкин. Чаңгы-биатлон комплексында күңел ачу чаралары да җитәрлек булачак.

ЧИРГӘ ЯЛ ЮК



Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа ел алдыннан республикада вируслы авыручылар саны кисәк артты. Дәвалау оешмаларына да, табибларга да эш икеләтә күбәйде. Шәхсән үзебезгә дә өйгә чакырткан балалар табибының килүен төнге сәгать уникегә кадәр көтәргә туры килде. Аңлап кабул иттек, билгеле. Аңа кадәр педиатрыбыз үзе дә алдан: «Авыручылар бик күп, өлгермибез, бүген бик соң гына килеп җитәрмен, мөгаен», – дип шалтыратып кисәтеп куйган иде.

Үл көннәрдә республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы да дәвалау оешмаларының көчәйтелгән режимда эшләвен, «ашыгыч ярдәм»не дә көне буе көтәргә туры киләчәге турында кисәтте. Бәйрәм ялларында исә вазгыять бераз тотрыклана төшкән. Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, быелның беренче атнасында республикада грипп һәм ОРВИ йоктыручының 17593 очрагы теркәлгән. Бу алдагы атна белән чагыштырганда 37 процентка азрак. Белгечләр моны озын Яңа ел яллары галәмәте дип бәяли. Көндәлек эш, уку режимы башлангач, гыйнвар азагында республикада вируслы чирләр йоктыручылар саны кабат артачак, дип фаразлый алар. Ник дигәндә, гыйнварда елның-елында шул хәл күзәтелә.

– Бүген күбрәк А тибындагы грипп очрый. Коронавируска бәйле вазгыять тотрыклы. Ковид белән авыручылар саны алдагы атна белән чагыштырганда 27 процентка азрак. Бәйрәм чорында халык дәвалау оешмалары юлын сирәк таптый. Декабрьнең соңгы атнасы белән гыйнварның беренче атнасында авыручылар саны кимү әнә шуңа бәйле, – диелә Роспотребнадзор хәбәрендә.

Яңа ел алдыннан белгечләр, якын арада илдә тридемия инфекциясе йоктыручылар саны да артырга мөмкин, дип куркыткан иде. Тридемия дигәндә алар ковид, грипп һәм тагын берәр респиратор чир (аденовирус, бокавирус һ.б.) белән берьюлы авыруны күздә тота. Барысының да билгеләре, нигездә, охшаш, ә нәтиҗәләре шактый аяныч булырга мөмкин, дип кисәтә белгечләр. Тридемия барыннан да бигрәк йөрәк-кан тамырларына, үпкәгә бәрүе белән куркыныч.

«ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән табиблар берьюлы берничә төрле вирус белән авыручылар саны аратирә очрый дип белдерсә дә, тридемиядән барлыгы ничә кешенең интегүе билгесез. Һәрхәлдә, Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсендә әлегә андый төгәл санны атамыйлар.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты, Республика клиник хастаханәсенең терапия клиникасы башлыгы Диана Габделганиева сүзләренә караганда, бу чир барыннан да бигрәк иммунитеты какшаган кеше өчен куркыныч.

– Бүген, дөрестән дә, бик күп кенә респиратор авырулар баш калкыткан чор. Кеше аларның һәркайсы белән аерым-аерым гына да, берничә төрле вирус белән берьюлы да авырырга мөмкин. Монда бар да иммунитетның ни дәрәҗәдә нык булуына бәйле. Әгәр дә кеше яңа гына авырып терелгән, иммунитеты какшаган икән, ул яңа вирусларга каршы тора алмаячак. Нәтиҗәдә кеше алдагысы белән чагыштырганда ныграк чирләргә мөмкин, – ди табиб.

Диана Габделганиева сүзләренә караганда, быел грипп та алдагы елдагылар белән чагыштырганда мәкерлерәк. Грипп белән авырып терелүчеләр арасында йөрәге, үпкәсе зәгыйфьләнеп калучылар шактый икән. Белгечләр февраль – март айларына республикада В тибындагы грипп өстенлек итәчәк дип фаразлый. Анысы җиңелрәк санала, аның белән авырган кешедә җитди өзлегүләр дә сирәк күзәтелә. Табиб искәртә:

> Вируслы чирләрдән саклану өчен прививка ясатудан да яхшысы юк. Кеше күп җыелган урыннарга битлек кимичә чыкмаска, кулларны-битләрне һәрчак юып торырга, урамнан кергәч, борын белән авызны яхшылап чайкарга кирәк. Бүлмәләрне җилләтеп торырга да онытмагыз. ОРВИлы кеше белән аралашырга туры килсә, алда әйтелгән киңәшләрдән тыш, борынга дару тамызып куюның да артыгы булмас.

10 нчы шәһәр балалар хастаханәсе баш табибы Лилия Мөхәммәтгатова яшерми: Яңа ел ялларын куркып көткән алар. Бу аңлашыла да. Декабрь азагында аралашканда, балалар арасында авыручылар саны кисәк кенә артып китү турында сөйләгән иде табиб. Ул чорда бер көн эчендә аларның хастаханәсенә караган 34 участокның һәркайсына 20ләп мөрәҗәгать килгән иде.

– Озын Яңа ел ялларын тыныч кына үткәреп җибәрдек. Соңгы ике атна эчендә бездә авыручы балалар саны уртача 1,4 тапкыр кимеде. Хәзер мәктәпләрдә укулар башлангач, авыручылар кабат акрынлап арта башлар дип торабыз, – ди Лилия Мөхәммәтгатова. – Әмма, ничек кенә булмасын, бу – сезонлы күренеш. Шуңа күрә ата-аналар хәвефләнмәсен иде. Баланың температурасы күтәрелсә, ул баш авыртудан зарлана икән, кичекмәстән табиб чакыртырга кирәк. Чөнки бу салкын тию генә түгел, бик күп кенә башка авыруларның да билгесе булырга мөмкин. Баланы үзең дәваларга маташу куркыныч. Вируслы авырулардан саклану өчен исә коронавирус өйрәткән гади генә кагыйдәләрне истә тотарга кирәк. Вакытында гриппка каршы прививка ясаткан кешеләр дә ота. Хәзерге вакытта грипп белән, нигездә, әнә шул прививкасы булмаган балалар авырый.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Язучы сүзе

Бәлки, файдасы тияр

Шәһәр кешесе бик алай түгел бугай инде ул, әллә мин генә аңлап бетерәлмимме, әйтеп булмый. Тик авылда бу мәсьәләдә бераз беркатлырак халык яши.

Килеп төшә менә бер абзый. Яхшы киенгән, күкрәген киереп, башын күтәреп, бөтен дөньяны үзе белән тотырырга тырышып атлый. Сүзен дә бөердән чыгара. Моны күрүгә үк кешеләр арасында чыш-пыш китә хәзер:

– Бик абруйлы кеше икән…

– Шәһәрдән үк килгән…

– Бай да икән…

Бу абзый шул рәвешле беренче күрүдән үк зур кешегә әверелә. Афтаритет! Әле беркемгә бер игелек кылмаган, хәтта якты йөз дә күрсәтмәгән, җылы сүз дә әйтмәгән. Кем икәнен дә төгәл белгән кеше юк. Шулай да аның үз-үзен тотышы шундук бөтен халыкны урынына утыртып куя, буйсынырга мәҗбүр итә. Кайберәүләр авызын колагына җиткереп ялагай елмаеп, ике кулын сузып күрешә:

– Рәхим итегез, бик вакытлы килдегез…

Кайберләре кунакка ук чакыра башлый. Һәм һәрберсе аңа ягымлырак булырга, якты йөз күрсәтергә, хөрмәт итәргә ашыга. Һәм һәрберсенең башында якты бер уй балкып бөтерелә: «Бәлки, файдасы тияр…»

Бу абзыйның файда китерергә сәләтлеме-юкмы икәнен дә белгән кеше юк әле. Тик кыяфәтенә караганда ул бик зур мөмкинлекләргә иядер кебек тоела. Бары тик аның рәхим-шәфкате төшәрлек дәрәҗәдә булырга гына кирәк…

Кайчагында андый абзыйларның файдасы тигәләп тә куя инде. Бөтенләй бер юне дә булмаса, ул кадәр үк өлтерәп тормаслар иде. Тик күп очракта сукыр бер тиенлек тә игелеге булмый. Күпләр өчен бу яңалык түгел. Барысы да диярлек мондый зур абзыйларның чынлыкта ул кадәр үк кодрәтле булып чыкмаганын, чыккан хәлдә дә бер файдасы тимәячәген, андый затларның йомшылы кавемгә артык исе китеп бармаганын алдан ук белеп тора. Авызлары бер генә тапкыр пешмәгән. Ә авызы пешкән кеше салкын катыкны да өреп каба. Салкын катыкны өреп каба, тик менә шундый абзыйларга алданудан тукталып кала алмый. Белмим инде аның хикмәте нидә икәнлеген. Берәр тылсымы бардыр, югыйсә ул кадәр үк кире каккысыз, тыелып калгысыз булмас иде. Мең тапкыр алдана ул шулай, ике мең, йөз мең кат алдана һәм йөз мең дә беренче очракта авыр көрсенеп: «Бәлки, монысының берәр файдасы тияр», – дип уйлап куя.

Бу авылга килгән агай белән генә чикләнми бугай инде. Без, гомумән, читтән килгән вәкарьлерәк кешеләргә гел шулай мөкиббән китәбез. Читтән килгән артистларга ат бәясенә билет алабыз. Читтән килгән китаплар акыллырак һәм кызыклырак булып тоела. Читтә яшәгән кешеләр бай, рәхәт тормышта яшәгән шикелле була. Шуңа без адым саен диярлек: «Вәт, менә Европада яшәп тә карыйлар икән! Америкада бомжлар да бездән хәллерәк икән!» – дип сокланып, тел шартлатабыз. Бәлки, чынлап та шулайдыр инде. Булсын. Безгә аның нинди хаҗәте бар? Бәлки, икенче галактикада алардан да рәхәтрәк яшәүчеләр бардыр, аннан бит безнең тормыш яхшырмый.

Югыйсә, үзен әллә кемгә исәпләп, борынын күтәреп кәперәеп йөрүчене түгел, ә үзебез кебек үк гади кешеләрне артыграк күрү, аларны хөрмәт итү әйбәтрәк. Бу гадел дә була, гади яхшылыкның бәясен дә күтәрә. Әгәр кемдер безгә килгән икән, үз дөньясын күтәреп кермәсен, безнеңчә булсын, безнең кануннарны санласын. Үзебезчә булсын. Булырга тырышсын. Юк, без андыйларны бар дип тә белмибез. «Һәй, шул да булдымы кеше! Бер кызыгырлык җире дә юк, үзебез кебек бер нәрсә инде шунда», – дип кул гына селтибез.

Ярый, җәмәгать, сүземне шушы урында өзеп торам, ярыймы. Сез мине гаепләмәгез инде… Әле бүлмәгә бер абзый керде. Килеш-килбәте дә, үз-үзен тотышы да бик зиннәтле, бик хөрмәтле затка охшаган. Бәлки…

– Әйдә, зинһар, түрдән узыгыз. Менә мондарак, йомшаграк урындыкка утырыгыз. Чәй эчәсезме, кофемы…

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Милли мәсьәлә

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне таныш булмаган берәү миңа рәхмәт әйтеп шалтырата. «Газетага сез язганнарны укыр өчен язылдым», – ди. Дөресен генә әйткәндә, газета эше шактый арыткан иде, бу рубриканы алып бару-бармау турында икеләнә дә башлаган идем. Менә бер укучыбызның миңа шалтыратуы бөтен икеләнүләрне юкка чыгарды да куйды.

Үзен «Хәмит Вәлиди» дип таныштырды ул. Әйтүенчә, «Казан утлары», «Чаян» журналлары, төрле газеталар редакцияләренә кереп йөри икән. Без кызыксынучан халык бит инде, «Чаян»га Алмаз Хәмзингә шалтыратып: «Шундый-шундый кешене беләсеңме?» – дип сорадым. «Гыйлемле кеше, иҗат кешесе, безгә дә шигырьләр калдырып киткәли», – ди Алмаз.

Мине аның шалтыратуы уйга калдырды. Хәмит әфәндене аерым бер кешенең язмалары гына түгел, гомумән, татар газета-журналлары язмышы кызыксындыра. Басма матбугатка язылучылар саны кимү дә борчый иде бугай.

Бу юлларны ни өчен язам? Бездә бит әле вакытлы матбугат язмышы өчен җаваплы кешеләр арасында газета-журналларны кулларына тотып карамаучылар да очрый. Ходай аларга бераз булса да Хәмит акылларын бирсен иде. Мин үзем милли матбугатны милли сәясәтнең аерылгысыз бер өлеше дип күзаллыйм.

Рәсми мәгълүматлар буенча бүген татарча 112 газета, 39 журнал нәшер ителә икән. 1905–1924 еллар белән чагыштырганда 2,5 тапкыр чамасы ким дигән сүз. Саннар белән башыгызны бутыйсы килми, узган гасырларда басма матбугатның мулдан нәшер ителүен нәкъ менә милли сәясәт, милли идеологиягә бәйлисе килә. Җәмгыятьтә нинди генә үзгәрешләр булмасын, хакимияткә кемнәр генә килмәсен – алар үзләренең сәясәтен киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә, аңлатып барырга тиеш. Үзен хөрмәт иткән хакимиятнең үз матбугат органнары, төрле мәгълүмат чаралары булырга тиеш.

Хакимият аларның кадерен белергә тиеш. Интернет заманында вакытлы матбугатның кадере кимергә мөмкин, бу табигый да. Шул ук вакытта рәсми сайтларны исәпкә алмаганда, интернет коткы таратуда да зур эш башкара. Моны хакимият үзе дә таный һәм ялган мәгълүматларга каршы аяусыз көрәшә. Үзе үк тудыра, үзе үк аны юк итә башлый – монысы да кызык, әйе бит!

Ә менә басма матбугат... Ул гомерләрәк булыр төсле. Бүген без әллә ничә гасыр элек язылган тарихи ядкарьләрне кадерләп саклыйбыз. Бераз катырак селкесәң таралыр хәлгә җиткән, саргаеп беткән төрле документлар, газета-журналлар – безнең өчен иң кадерле мирас.

Без – газета чыгаручылар, аны укучылар, газета белән хезмәттәшлек итүчеләр – олы үзгәрешләрнең шаһитлары. Алай гына да түгел, тарих язуга, һәр чорның милли сәясәтен тормышка ашыруга шактый ук дәрәҗәдә үз өлешебезне кертүчеләр.

Газета-журналлар милләтебезне, телебезне саклауга да зур өлеш кертә. Күптән түгел «Тәртип» радиосыннан Татарстанның Петербургтагы һәм Ленинград өлкәсендәге даими вәкиле Ренат Вәлиуллин белән әңгәмә тыңладым. Ул Петербург халкы турында кызыклы гына сүзләр әйтте. Бу кала халкы рухи байлыкны матди байлыктан өстенрәк күрә икән. Һәр гаилә атна саен концерт-спектакльләргә бара, ди. Җәмәгать транспортында, метрода йөрүчеләр безнең кебек телефонга чукынып утырмыйлар, ә газета, китап укыйлар икән. Боларны ишеткәч, көнләштем дә, гарьләндем дә. Иң мәгърифәтле халыкларның берсе булып тарихка кереп калган татарымны уйлап куйдым. Бүген безгә, күрәсең, газета-журнал язмышын үз язмышы итәргә омтылган шәхесләр җитми. Ә синә, Хәмит дус, күңелдә шундый уйлар тудырган өчен рәхмәт.

СЫЕРЛАР КЛИМАТКА КАРШЫ,

ЯКИ НЕМЕЦ ФЕРМЕРЛАРЫ НИ ТЕЛИ?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Бу язманың авторы яшь вакытта, бернинди актерлык сәләте булмаса да, бер татар язучысының пьесасын сәхнәләштерүдә катнашып, төп рольләрнең берсен уйнап йөргән иде. Ятланган сүзләр күптән онытылган инде, әмма бер персонажның репликасы әле дә хәтердә. «Кызык хәлләр творятся бу дөньяда», – ди ул, тамашачыга карап. Утыз биш еллап вакыт үткәч, нинди хәлләр «творятся» итәсен әйтсәләр, ул чакта безнең чәчләр үрә торыр иде.

Әйтик, мәсәлән, Швециядәге Лунд университеты һәм Канададагы Британ Колумбиясе университеты тикшерүчеләре парник газлары чыгаруда иң зыянлы нәрсәләрне ачыклаган. Болар: шәхси автомобильләрдә йөрү, самолетларда сәяхәт итү, итле ризыклар ашау һәм... бала табу. Европада «экологик баласызлык» дигән термин киң тарала хәзер, урамнарда «яшелләр» бала тапмаска өндәгән плакатлар элә, сабыйларны «климатны үтерүчеләр» дип атый. Көнбатышта демографик һәлакәт көчле темп алып ята бүген, һәм без каршы түгел: үзләре теләгәч, юкка чыксыннар, тик идеяләрен бар планетага көчләп такмасыннар гына.

Итле ризыклар мәсьәләсен аңлый торгансыздыр инде: итнең төп чыганагы булган сыерлар метанны кеше баласына караганда да күбрәк чыгара. Сыер тиресе бездә дә куркыныч калдыклар исемлегендә һәм Дәүләт Думасының гасырлар буе экологик яктан чиста булып саналган бу ашламаны ул исемлектән чыгарырга омтылуы «Гринпис» һәм Росприроднадзор тарафыннан көчле каршылыкка очрады.

Киләсе атнада Давоста Бөтендөнья икътисад форумы ачылачак. Форум кысасында «C40 Cities» инициативасы карала. Дөньяның зур шәһәрләре мэрлары климат кризисына каршы көрәшкә берләштеләр дә берләшмәләрен шулай атадылар. Күрәсең, башта кырык мэр аркадашлык иткәндер. Хәзер аларның саны – 96. Менә шул «C40 Cities» «2030 елга бернинди ит тә, сөт тә булмасын» дигән идеяне байрак итеп күтәрде инде. Алар шулай глобаль җылынуга каршы көрәшәбез дип саныйлар. Искәртик: бер Россия шәһәре дә һәм компаниясе дә бу оешмада катнашмый. Бу – изоляциянең бер уңай ягы. «Ит һәм сөт булмагач, без нишләрбез?» – дигән уй башыгыздан ялтырап узгандыр. Шатланыгыз: Давос кешеләрнең дә кирәге юк дип саный. Бөтендөнья икътисад форумының әйдәп баручы киңәшчесе Юваль Ноа Харари: «Без хәзер зур күләмдә файдасыз кешеләр сыйныфы барлыкка килүен күрәбез. Компьютерлар төрле өлкәләрдә камилләшкән саен, аларның бездән бик күп мәсьәләләрне чишкәндә өстен чыгу мөмкинлеге бар. Һәм алар кешеләрне кирәксезгә чыгарачак. Шул чакта XXI гасырның төп сәяси һәм икътисадый мәсьәләсе булып: кешеләр безгә ни өчен кирәк дигән сорау торачак», – дип чыгыш ясады инде.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Акылдан язганнарның мондый идеяләре куркыта, билгеле. Фикернең рәсми коралланута алынуы бер дә шәп нәрсә түгел. Бу безгә бик зур проблемалар тудырачак. Юк, сез алай төшенкелеккә бирелергә ашыкмагыз. Кешелек җәмгыяте алай җиңел генә бирелергә җыенмый. Иткә һәм сабыйларга каршы көрәш фронтында иң беренче зыянны кемнәр күрә? Дөрес әйтәсез: фермерлар. Европада фермерларны юк итү сәясәте күптән бара инде. Ясалма ит һәм башка төр продуктлар җитештерүче стартаплар гөмбә урынына үрчергә җыена. Аларны финанслыйлар, өстенлекләр бирәләр. Базарга ясалма ит чыктымы, фермерлар үзләреннән-үзләре юкка чыгачак дип уйланыла. Натураль продуктлар җитештерү икътисадый яктан отышсыз була башлагач, кая барасың? Ә итне аны, гафу итегез, бәдрәф шакшысыннан да җитештереп була. Технологияләр! Компьютерның эзләү системасына «мясо из фекалии человека» дип язып карагыз әле... Большевиклар чорында, әйтик, спиртны тирестән һәм бәдрәф калдыкларыннан куу тәҗрибәсе бар. Пролетар шагыйрь Демьян Бедный бу хакта шигырь дә иҗат иткән. Шигырен газетага бирерлек түгел ләкин.

Европалы фермерлар зыян күрүләре беләнризалашмый, әлбәттә. Алар принципиаль рәвештә көрәшкә чыга. Бу дүшәмбедә немец фермерлары масштаблы протест акциясенә күтәрелде: алар автотрассаларны бикли, шәһәр урамнарына китереп тирес бушаталар... Көрәшнең беренче сәгатьләрендә үк: «Мюнхенга таба 5500 трактор юнәлде», «Коттбус озакламый тышкы дөньядан бикләнәчәк», «Чехия белән чик ябылды», – дигән хәбәрләр күренде. Эмденда Volkswagen җитештерү туктатылды, чөнки фермерлар заводка керү юлларын бикләде. Ягулык белән өзеклекләр бар, нефть эшкәртү заводларына шулай ук барып булмый. Фермерларның төп таләпләре дә дизель ягулыгына бәйле. Шольц хакимияте ягулыкка субсидияләрне бетергәч, продукция җитештерү мөмкин булмый башлады, чөнки сатып алу бәяләре ташка үлчим.

Дрезденда «Яшелләр» партиясе вәкиле Карл Бэр депутат буларак халык алдында чыгыш ясарга омтылып караган иде, 8 меңләп кешенең сызгыруы һәм: «Юк бул!» – дип кычкыруы астында табан ялтыратырга мәҗбүр булды. «Яшелләр» партиясенә фермерларның үче ни өчен зур булуын аңлыйсыздыр дип уйлыйм. Телеграм-каналларда икътисад министры һәм «Яшелләр» партиясе әгъзасы Роберт Хабек утырган паромны фермерлар штурмлавы төшерелгән видеоны карый аласыз. Сәясәтче чак качып котылды, диделәр.

Фермерларның ярсуы сәбәбен аңлау кыен түгел. Гессен фермеры җирле парламентарийларга моны болай аңлата: пестицидларсыз үстерелгән бәрәңгенең йөз килосын арадашчыларга 3,5 еврога гына сатып була (безнең акча белән килосы 4 сумнан арзанрак). Андый бәяләр белән ерак китеп булмаячагын аңлау кыен түгел. Немец крестьяннары соңгы чиккә килеп терәлгәннәр һәм бик үчле. Икътисадый гына түгел, сәяси таләпләрне дә бик кыю куялар: «Шольцны – Себергә, Путинны – Берлинга» дигән тавышлар яңгырый.

Дилемма бит сызылган: я фермерлар җиңә дә эшләрен дәвам итә, яисә сыйныф буларак юкка чыгалар. Алар урынына ясалма азык җитештерүче компанияләр килә. Йөз эре компания кибет киштәләреннән итне һәм сөтне алып ташларга җыена дип югарыда әйттек бит инде. Европалылар майларына чыдый алмый дип уйламагыз. «Европа барометры: европалыларның 38 проценты көнгә өч тапкыр ашый алмый. Финанс хәле рөхсәт итми», – дип яза социаль челтәрләр.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

ИКЕ КАБЫП, БЕР ЙОТУ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

30 мең сумлык табын

Чаллыда яшәүче Гөлфирә Исламова эштә дә, өйдә дә – бухгалтер. Дүрт кешелек гаиләнең бөтен чыгымнарын, үзе әйтмешли, «амбар кенәгәсе»нә язып бара ул.

– Балачак еллары ачлык заманына туры килгәнгәме, әбием гел: «Ашыңа ни салсаң, кашыгыңа шул чыгар», – дип әйтә торган иде. Шуңа күрә ашау-эчүгә акчаны кысып тота белмим. Бигрәк тә балаларга. Олы кызыбыз башлангыч сыйныфта укый, кечкенәсе балалар бакчасына йөри. Алар өчен төрле сөт ризыкларын да, тәм-томны да еш сатып алабыз. Өстәлнең буш торганы юк, кыскасы. Узган декабрь аенда гына да азык-төлеккә 28 мең сумга якын акча тотылган. Яңа ел табынын исәпкә алмаганда бу. Атна саен уртача 6–7 мең сумлык ризык ашаганбыз. Шунысы да бар: әлеге чыгымнарга мәктәптә һәм балалар бакчасында ашауга киткән акча да керә. Алдагы елның декабрендә, мәсәлән, ашау-эчүгә 22 мең сум чамасы акча тотылган булган.

Бер ел эчендә кайсы төр азык-төлеккә бәяләр аеруча арткан икәне дә билгеле. Беренчелек йомыркада, әлбәттә. Росстат мәгълүматларына караганда, былтыр алтынга тиң йомырка 85 процентка диярлек кыйммәтләнгән. Ел дәвамында помидор һәм бананның һәркайсы – 59, тавык ите һәм кәбестә хакы 33 процентка арткан. Сөт һәм ит ризыклары бәясе сизелерлек үзгәрмәсә, карабодай һәм бәрәңге бераз очсызланган да әле.

Халык арасында үткәрелгән сораштыру мәгълүматларына караганда, илдә яшәүчеләрнең 60,4 проценты айлык хезмәт хакының яртысын диярлек азык-төлек сатып алуга тота. Респондентларның 15 проценты азык-төлек кибетендә айлык акчаның өчтән берен туздыруын, ә 16 проценты исә тамак хакына гына эшләвен әйткән.

Бу хакта сөйләгәндә яшәү минимумы турында да искә алыйк. Бу – кешегә бер ай буе яшәү, дөресрәк әйтсәк, җан асрау өчен кирәкле минималь акча күләме. Әлеге күрсәткечкә азык-төлек, товарлар һәм хезмәтләр дә керә. Быел Татарстанда яшәү минимумының уртача күләме 169 сумга артып, 13135 мең сумга җитте. Аерым алганда, эшкә яраклылар өчен ул – 14317 сум, балаларга – 12741 сум, ә пенсионерларга 11296 сум тәшкил итә.

Республикада яшәүчеләрнең күпме хезмәт хакы алуы да мәгълүм.

– 2024 елның 1 гыйнварыннан Татарстанда бюджеттан тыш сектор өчен минималь хезмәт хакы 22 мең сум чамасы тәшкил итәчәк. 2023 елның тугыз ае нәтиҗәләренә караганда, республикада хезмәт хакының уртача күләме – 59223 сум, – диде хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова узган ел азагында.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чапма, бәя!

Ничек кенә булмасын, халыкның керемнә караганда чыгымнары тизрәк үсә, ди Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов.

– Медицина өлкәсендә кешенең сәламәтлегенә бәйле гомуми туклану нормалары бар. Анда күпме ит, сөт ризыклары ашарга кирәклеге күрсәтелгән. Кибеттәге бәяләр белән исәпләп караганым бар, табиблар кушканча туклансаң, бер кешегә азык-төлеккә аена 12–13 мең сум акча кирәк. Пенсионерларны алсак, аларның айлык акчасы шул ашауга гына җитәчәк. Әле бит ТКХ, дару сатып алу, юл чыгымнары кебек башка төр мәҗбүри түләүләр дә бар. Ике бала тәрбияләүче дүрт кешелек гаиләне алсак та, аларның айлык керемнәренең яртысы ашау-эчүгә китү – гадәти хәл. Югыйсә икътисадый күзлектән чыгып караганда, әлеге төр чыгымнар гаилә бюджетының дүрттән береннән артмаска тиеш, – ди белгеч.

Азык-төлек киштәсендәге бәяләрнең ни өчен үсүен дә аңлатты ул.

– Итне, икмәкне үзебездә җитештерәбез, дип сөйләргә яратабыз. Тик авыл хуҗалыгы предприятиеләре – чимал җитештерүчеләр генә. Шул ук сөтне, бөртекләрне күмәртәләп эшкәртүчеләргә саталар. Алар исә үз чыгымнарын бәягә сала. Җитмәсә, күбесе кредит хисабына эшли. Ә Үзәк банк төп ставканы былтыр 16 процентка кадәр күтәрде. Кредит оешмалары исә бурычка акча биргәндә үзләреннән тагын 5–6 процент өсти. Боларның барысы да ахыр чиктә киштәдәге азык-төлек бәясендә чагыла, – ди Илгизәр Гайнетдинов. – Кызганыч, Хөкүмәт әле дә бәяләрне үстерү сәясәтен алып бара. Безнең Тарифлар буенча дәүләт комитеты да бар бит. Тик мин аларның беркайчан да бәяләрне киметү юнәлешендә эшләгәннәрен белмим. Бәяләр артканны гына аклап утыралар. Бәяләрне Хөкүмәт тарафыннан йөгәнләмәсәләр, без һаман да шул инфляция артыннан куучы бәяләр артыннан чабачакбыз. Ә реаль хезмәт хаклары, пенсияләр инфляция күрсәткечен куып тота алмый. Безнең товар сатып алу мөмкинлеге артмады, киресенчә төште.

Бушлай сыр... тәбәдә түгел

Алга таба дөге боткасы да тансыкка әйләнмәгәе. Белгечләр, әлеге төр ярма быел 20 процентка кадәр кыйммәтләнергә мөмкин, кип кисәткән. Сәбәбен дә әйткәннәр: күпләп дөге үстерүче Һиндстан һәм Тайландта былтыр уңыш начар булган. Шуңа күрә товарны читкә озатуга, гомумән дә, вакытлыча чик куйганнар. Ел башында азык-төлек кибетләрендә шоколад, сөт ризыклары һәм спиртлы эчемлекләр дә 10–15 процентка кадәр артырга мөмкин. Бәяләргә әлеге дә баягы логистика, доллар кыйммәтләнү тәэсир итә.

Сөенечле яңалык та бар: Дәүләт Думасы депутатлары кибетләрдә куллану вакыты чыга торган азык-төлекне бушлай таратырга тәкъдим иткән. Яңалык пенсионерларга һәм аз керемлеләргә кагыла. Закон проекты хуплау тапкан очракта, кибетләрдә махсус киштәләр пәйда булачак, янәсе. Куллану вакыты чыга торган азык-төлекне бушлай алу өчен пенсионер яки аз керемле булу турындагы документны күрсәтергә туры киләчәк, дип тә искәрткәннәр.

Яңалыкны тәкъдим итүчеләр әйтүенчә, бүген илдә җитештерелгән ризыкның өчтән бере чүп чиләгенә оча. Ел буе 30 миллион кешене ашатырга җитәрлек 1,6 триллион сумлык 17 миллион тонна товар дигән сүз бу! Барыннан да бигрәк, яшелчә, икмәк һәм сөт ризыклары исраф ителә, дигәннәр. «Кибетләрдә социаль киштәләр булдыру – ирекле эш, мондый сәүдә ноктааларына ташламалар да биреләчәк», – дип вәгъдә иткән депутатлар. Яңалыкка сатучылар гына шикләнеп карый.

– Куллану вакыты чыга торган товарны ташлама белән сатып бетерергә тырышабыз. Кала икән, аны документлар нигезендә утильләштерәбез, ягъни товар белән тәэмин итүчегә кире озатабыз. Ул, мәсәлән, шул ук сөт ризыгын янәшәдәге чүп контейнерына чыгарып атамы, әллә берәр хуҗалыкка терлек азыгы буларак озатамы, аның эше. Кибет тиктомалдан гына хәйриячелек белән шөгыльләнә алмый, – ди башкаладагы супермаркетларның берсендә директор урынбасары булып эшләүче Диана Шәрәфиева. – Гомумән алганда, без яңалыкка каршы түгел. Бушка килгәнне кем дә ярата.

Фикер

Елена БОНДАРЕНКО, «Иҗтимагый фикер – Татарстан» фонды җитәкчесе урынбасары:
– Илдә инфляция күрсәткече 8–9 процент дип әйтәбез икән, аның уртача күрсәткеч булуын да истә тотарга кирәк. Катер яки бриллиант таш кебек зәвыклы товарларның бәясе әллә ни үзгәрмичә, азык-төлек һәм беренчел ихтыяҗ кирәк-яраклары 20–30 процентка кадәр артты. Соңгысы илдә яшәүче күпчелек халыкка кагыла. Статистика мәгълүматларына караганда, бүген россиялеләрнең 9–29 проценты урта катлауны тәшкил итә. Димәк, моннан да начаррак яшәүчеләр күбрәк. Алар өчен ашау-эчү, ТКХ өчен түләү кебек төп чыгымнар гаилә бюджетының шактый өлешен алып тора. Шуңа күрә депутатларның пенсионерларга һәм аз керемлеләргә куллану вакыты чыга торган азык-төлекне кибетләрдә бушлай өләшү тәкъдимен хуплыйм. Кибет янәшәсендәге чүп контейнерында актарынганчы, киштәдән алып китү хәерлерәк. Хәзер яшьләр арасында шундый экологик хәрәкәтләр дә бар. Алар социаль челтәрләрдә аерым төркемнәргә берләшеп кайда нинди куллану вакыты чыга торган товар барлыгын белешәләр дә, сок яки сөт ризыгын шуннан бушка барып алалар. Акча юклыктан түгел, ә табигатькә зыян салуны киметү һәм куллану психологиясен үзгәртү өчен шулай эшлиләр. Соңгысы безгә Көнбатыштан киләдер. Чит илдә секонд-хендта киенүнең бернинди ояты да юк бит. Киресенчә, байлар да шуннан кием сатып ала. Ә җыелган акчаны еш кына хәйриячелеккә тоталар. Безгә дә әнә шул культураны алга сөрергә кирәк. Кибет киштәсеннән куллану вакыты чыга торган азык-төлекне алуның бернинди дә хурлыгы юк. Бу – икътисадый яктан отышлырак та әле.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

САЛАМ ТҮШӘҮ

Миңа кагылмас әле. Теге яки бу әйберне иминиятләштерүгә килгәндә, күпчелегебез әнә шулай фикерле. Ләкин белгечләр һәм зыян күрүчеләр белән сөйләшкәч, бәла-каза килгәнче, саламны алдан түшәп кую кирәклерәк булуына инандык.

«Файдасын күрдек»

2017 елда Азнакай районының бер авылында зур янгын чыга. Янәшә торган ике йорт кыска гына вакыт эчендә көлгә әйләнә. Көчле җил булу сәбәпле, ялкын телләре күршедәге башка йортларга да үрмәли, тик, бәхеткә, авыл халкы, янгын сүндерүчеләр ярдәме белән аларын саклап калалар. Шул хәлләрдән соң Зәлия Ибраһимова ел да йортларын иминиятләштерә башлый.

– Ул елны йортыбыз иминиятләштерелмәгән иде, ут телләре коймага кадәр үрмәләгәч, бик курыктык. Әле ярый күршеләрнең яхшы йортлары иминиятләштерелгән булган, 1 млн сум иминият түләвен алдылар. Бу хәлләр безгә дә сабак булды. Дөрес, аңа кадәр дә мин мунчаны һәм терлекләрне иминиятләштерә идем. Янгын афәтен 2000 елда үзебезгә дә күрергә туры килде. Мунчабыз тулысы белән янып бетте. Эчендәге барлык әйберләре иминиятләштерелгән иде. Түбәсе ябылган бура, такталар сатып алырлык иминият түләве кәтте. Эштән дә ярдәм иттеләр. Шул акчага яңа мунчаны тиз сафка бастырдык, – ди ул.

Озак еллар терлекләрен дә иминиятләштереп барган укучыбыз. Берничә тапкыр түләүләрен кайтарырга да туры килгән. Тик бер елны ниндидер билгесез кешеләр сыерларын урманга алып китеп суйгач, иминият түләүләрен кайтармаганнар.

– Ул вакытта ярты хакын гына түләгән булганбыз, шул сәбәпле урланган сыерыбыз өчен акча ала алмадык. Шуннан соң терлекләрне иминиятләштергәнебез юк. Ә менә йорт, башка каралты-куралар, коймалар – барысы да азмы-күпме сакланган. Минем фикеремчә, ул – кирәкле гамәл. Билгеле, ул түләүләр килгән зыянны берничек тә каплап бетерә алмас, тик бер тиенсез урамда калган ише булмас. Ничек кенә булса да, ут-ялкынны башка күрергә язмасын, – ди Зәлия апа.

Узган елны Насыйбуллиннар гаиләсе дә янгыннан зыян күргән. Көзен мунчалары янып беткән аларның.

– Мунчаны, 6 мең сум акча түләп, эчендәге милкеннән тыш кына иминиятләштергән идек. Иминият түләвен 100 мең сум алдык. Күбрәк суммага иминиятләштергән булсак, зуррак акча аласы идек, билгеле. Ләкин бу акча да блоклар, такталар, ком, цемент ише төзелеш материалларын сатып алырга җитте. Күпчелек эшен балалар белән үзебез эшләгәч, яңа мунчаны сафка бастырыр өчен артык зур акча тотылмады, – диде ул.

Терлек кадерле

Балтачта яшәүче иминиятләштерүче агент Гомәр Каюмов әйтүенчә, халык арасында берничә төре иң популярлары булып санала. Аларның берсе машина ОСАГОсы булса, икенчесе – милекне иминиятләштерү.

– Хәзер бөтен кешедә машина бар һәм аны эшләү мәҗбүри. КАСКОны бик аз гына кеше эшләтә. Гадәттә алар бик акчалы яки үз-үзенә ышанычы булмаган кешеләр була. Яисә аны банклардан кредит алган вакытта мәҗбүри эшләттерәләр, – ди ул.

Моннан тыш, халык фатир, йорт, дачаларын да күпләп иминиятләштерә. Авылларда янгын чыгып, бер тиенсез урамда калудан куркып, йортларын иминиятләштерүчеләр якынча 95 процентны тәшкил итә, ди белгеч.

– Гражданлык җаваплылыгы дигәне дә бар. Әйтик, иминиятләштерелмәгән яки башка оешма белән килешүе булган бер дачада чыккан янгын күршесенекенә күчә икән, аңа килгән зыянны да каплау мөмкинлеген бирә ул. Иминиятләштерүнең шул төрен сайлаучылар да шактый, – ди Гомәр Каюмов.

Шулай да авылларда иң популяр иминият төре терлекләргә кагылышлысы икән. Моннан мал тоткан авыл халкының 90 проценты файдалана ди.

– Кешеләр үз сәламәтлекләрен, гомерләрен иминиятләштермәсә иминиятләштерми, тик терлеген беренче чиратта кайгырта, – ди Гомәр Каюмов. – Мал авырып, кинәт үлеп киткән, көтмәгәндә чалырга туры килгән очракларда, хуҗалары акча алачак дигән сүз. Әйтик, 100 мең сумга иминиятләштерелгән сыер үлеп китә икән, ите 40 мең сум тирәсе чыкса, 60 меңен иминият компаниясе түли.

Белгеч әйтүенчә, иминият компанияләре өчен ОСАГО иң чыгымлылардан санала. Якынча 25–30 процент очракта кешеләр иминият акчасын кайтара. Терлекләрен иминиятләштерүчеләрнең якынча 35–40 процентына түләүләрен кайтарырга туры килә. Милекне иминиятләштерүчеләр арасында клиентларның 3–5 процентына зыян килергә мөмкин икән. Бәхетсезлек очраклары буенча килешү төзегәннәр исә полисларын 10–15 процент очракта файдалана.

Идар Мөхәммәтҗанов

ИМИНИЯТЛӘШТЕРЕРГӘ КИҢӘШ ИТЕЛӘ ТОРГАН 4 ОЧРАК



1. ГОМЕР ҺӘМ САУЛЫК

Бу төр иминият авыр җәрәхәт алган, инвалид калган һәм төрле куркыныч авырулар белән авырган очракта акча алу мөмкинлеген бирә. Шунысына басым ясарга кирәк: түләү иминиятләштерелгән зат медицина ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән очракта гына түләнә. Клиент һәлак булган очракта, аның акчасын якыннары ала ала. Шулай ук килешү вакыты чыккач (5–10 ел), индексацияләнгән акчаны кире кайтару мөмкинлеге дә бар.

2. КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

Янгын, су басу, давыл, яшен сугу, көнкүрештә кулланыла торган газ чыгу, җир тетрәүләр, һәртөрле аварияләр, урлау, талау һәм вандализмнан килгән зыянны капларга ярдәм итә.

3. ТРАНСПОРТ

Машинаны авариядән, урлап китүдән килгән зыянны каплар өчен булыша. Шулай ук өченче затлар зыян китергән вакытта иминият түләүләрен алырга мөмкинлек бирә. Транспорттан тыш, машина йөртүчене һәм пассажирларны, хәтта кайбер очракларда багажны да иминиятләштерергә мөмкин.

4. БӘХЕТСЕЗЛЕК ОЧРАГЫ

Бу очракта иминият түләвен алыр өчен хезмәткә яраклылыкны вакытлыча яки даими рәвештә югалту түгел, ә саксызлык аркасында яки бәхетсезлек очрагында алган гади генә җәрәхәт тә сәбәп була ала. Шулай итеп, моны берәр төрле транспорт аркасында алынган җәрәхәт, ток сугу, агулану, суга бату, туңу, бандитлар яки агрессив хайваннар һөҗүме, пешү яки кояш сугудан алган зыянны каплар өчен файдаланырга була.

Ашыкмыйлар

Казанның бер туристлык агентлыгында эшләүче Ләйсән Гайфетдинова әйтүенчә, туристларның бик азы гына мәҗбүри булмаган иминияттән файдалана.

– Чит илгә барган туристларны һәрвакытта да мәҗбүри иминиятләштерәбез, бу авырып киткән очракта медицина ярдәме алу өчен кирәк. Әйтик, минем эш тәҗрибәмдә бер клиентым квадроцикл астында калып, хастаханәгә эләккән очрак булды. Ә менә чит илгә чыкмаган очракта алына торган иминият (страховка от невыезда за границу) дигәнен турист бары тик үз ихтыяры белән генә сатып ала. Әгәр билгеле бер сәбәпләр аркасында сәяхәт өзелә икән, иминият компаниясе тур бәясен кайтарырга тиеш булып чыга. Тик моның да үз нечкәлекләре бар, килешүгә кул куйганда туристларга игътибарлы булырга киңәш итәбез. Гадәттә, мондый төр иминиятне балалары белән ял итүчеләр, юлламаны шактый алдан алып куючылар эшләтә, – ди белгеч.

Кызганыч, мал-мөлкәтләрен иминиятләштереп, бәла килгәч, ярык тагарак алдында калучылар да бар. Мондый хәл, гадәттә, килешүдәге шартлар белән яхшылап танышмау аркасында килеп чыга, ди белгечләр. Иминият компанияләре акча түләмәс өчен, җаваплылыкны клиентның үзенә аударып калдырган очраклар да юк түгел. Шуңа күрә чүп өстенә чүмәлә өелмәсен өчен, документларга кул куйганчы, барлык нечкәлекләрне кат-кат белешергә, сорауларга төгәл җаваплар алырга кирәк. Һәм, билгеле инде, полис артыннан тикшерелгән, ышанычлы оешмаларга гына мөрәҗәгать итү хәерле.



СЕЗ НӘРСӘНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРӘСЕЗ?

Фатирны/йортны	54,43%
Сәламәтлекне	12,66%
Барысын да	13,92%
Берсен дә иминиятләштермим	18,99%

Газетаның «ВК» сәхифәсендә уздырган сораштыру нәтиҗәләре

ФАРАЗ ҺӘМ ӨМЕТ

ЯСАЛМА АКЫЛ БЕЗГӘ НИНДИ КИЛӘЧӘК ЮРЫЙ?

Ел азагында, гадәттә, икътисадчылар, астрологлар, күрәзәчеләр киләсе елга фараз ясый, яңа елның нинди буласын чамаларга тырыша. Без бу эшне ясалма акылга йөкләдек. 2024 елда Россияне, аерым алганда Татарстанны ни көтә? Ел нинди үзгәрешләр алып килер? Шул хакта ясалма акылдан сораштык.

:: 2024 елда Россия халкын нәрсә көтә?
– 2024 елда Россиядә кайбер вакыйгалар һәм үзгәрешләр көтелә.

1 **Президент сайлау.** 2024 елда чираттагы сайлау узачак. Бу сәяси үзгәрешләргә, шулай ук илнең тышкы һәм эчке сәясәтендәге үзгәрешләргә китерәчәк.

2 **Икътисадый үсеш.** Реформаларны дәвам иттерү һәм Россия икътисадын үстерү планлаштырыла. Яңа инвестиция проектлары һәм бизнеска ярдәм чаралары кирәргә мөмкин.

3 **Социаль үзгәрешләр.** Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәме системасын үстерү, яшәү шартларын һәм халыкны социаль яклау өлкәсен яхшырту көтелә.

4 **Илкүләм проектларны тормышка ашыру.** Хакимият вәкилләре сәламәтлек саклау, мәгариф, торак, инфраструктура өлкәләрендәге илкүләм проектларны тормышка ашырырга омтыла. 2024 елда бу юнәлештә эш дәвам итәчәк.

5 **Халыкара мөнәсәбәтләр.** Россия башка илләр белән элемтәләрне үстерәчәк һәм халыкара чараларда катнашачак. Көнбатыш белән мөнәсәбәтләрне җайга салу юнәлешендә эш дәвам итәчәк.

:: Ә Татарстанны һәм Казанны 2024 елда нәрсә көтә?

1 Быел медицина үзәкләре, супермаркетлар, юллар һәм җәмәгать транспорты кебек яңа инфраструктура объектларын төзү һәм ачу ниятләнә.

2 Туризм өлкәсендә дә үсеш фаразларга була, чөнки Казан үзенең тарихи һәм мәдәни истәлекле урыннары белән дан тота. 2024 елда халык яңа туристик маршрутлар, яңа чаралар һәм күңел ачу урыннары белән таныша алачак.

3 Татарстан мәгариф һәм фән өлкәсен үстерүгә көч куячак. 2024 елда яңа уку йортлары, фәнни-тикшеренү үзәкләре ачу планлаштырыла.

4 2024 елда дәүләт органнары өчен сайлаулар оештырылачак, сәяси үзгәрешләр булырга һәм яңа лидерлар килергә мөмкин.

Бу – 2024 елда татарстанлыларны һәм Казан халкын көткән кайбер вакыйгалар һәм үзгәрешләр генә. Нәтиҗә сәяси һәм социаль кәефкә, төбәкнең планнарына һәм программаларын тормышка ашыруга бәйле булачак.

:: Быел Россия Президентын сайлаячакбыз. Анда кем җиңәр?
– Бу – безнең ил өчен иң актуаль һәм фикер алышу өчен җирлек тудыра торган сорауларның берсе. Традиция буенча, Россиядә Президент ярышы һәрвакыт киеренке һәм дулкынландыргыч була, чит илләрнең дә игътибарын җәлеп итә. 2024 елда төрле сәяси партияләрнең кандидатлары арасында югары вазыйфаларда эшләү тәҗрибәсе булган сәясәтчеләр дә, сәяси көрәшкә керергә әзер булган яшь, перспективалы лидерлар да бар.

:: 2024 елда Татарстанда нинди яңа фильмнар чыгачак?
– Кино сәнгатен сөючеләрне 2024 елда яңа фильмнар көтә. Быел Татарстан киноиндустриясе үз тамашачыларын гына түгел, Россиянекеләрне һәм аннан читтәгеләрне дә җәлеп итәргә тели. 2024 елның иң көтелгән проектларының берсе – татар халкының милли үзаңын һәм мәдәниятен формалаштыруның катлаулы юлы турында сөйләүче яңа тарихи драма. Фильм борынгы чордан алып бүгенге көнгә кадәр вакытны үз эченә ала. Профессионаллар командасы сыйфатлы фильмнар гына чыгарып калмыйча, аларда татар мәдәниятенең үзенчәлекләрен һәм мохитен бирергә тырышачак. Түземсезлек белән көтегез!

P.S. *Әлеге язма бары замана технологияләрен сынап карау максатыннан гына әзерләнде. Киләчәкнең нинди буласы фәкать үзебездән тора!*

shedevrum.ai

Илдар Мөхәммәтҗанов

ӨЙГӘ ЭШ

ТАТАРСТАН МӘКТӘПЛӘРЕ ЯҢАРТЫЛГАН ЭЛЕКТРОН БЕЛЕМ БИРҮ ПРОГРАММАСЫНА КҮЧӘ

Бу арада мәктәп яшендәге баласы булган әти-әниләрнең башлары әйләнгән: укучыларны яңа электрон программада теркәргә, гади итеп әйтсәк, яңа электрон көндәлеккә керергә кирәк. Әйтүе генә җиңел, кышкы каникулдан соң бөтен кеше берьюлы кесә телефонына ябырылгач, система, гомумән дә, начар эшли башлады. Тик көндәлексез дә булмый. Аптыраштa калган әти-әниләрне түрәләргә тынычландырырга туры килә.

Татарстан мәктәпләре яңартылган электрон белем бирү программасына күчә. Хәзер ул ms-edu.tatar.ru порталында урнашкан. Ә анда өр-яңадан теркәлергә кирәк. Әнә шул әти-әниләр арасында ыгы-зыгы китереп чыгарды да инде. Программага фәкать РФ Дәүләт хезмәтләре порталы аша гына кереп була. Ул очракта да «шәхси кабинет» аша гына. 14 яшь һәм аннан зуррак укучыларга җиңелрәк. Аларның күбесенең Дәүләт хезмәтләре порталында «шәхси кабинет»лары бар инде. Ә менә 14 яше тулмаганнарны әти-әниләр үз «бит»ләре аша терки. Бөтен кеше берьюлы интернетта мәгълүмат тутыра, система кирә башлагач, ә әти-әниләргә бу хакта кышкы каникулдан соң хәбәр иттеләр, программа «аксый» башлады.

– Дүртенче сыйныфта укучы кызымның шәхси мәгълүматларын Дәүләт хезмәтләре порталы аша раслый алмыйм. Аның туу турындагы таныклыгы моңарчы биредә теркәлгән булса да, хәзер аның туу урыны дип СССР тора. Техник ярдәм күрсәтү хезмәтенә шалтыраткан идем, программа «саташкан» дип кенә җавап бирделәр, – дип сөйли Казанда яшәүче Гөлназ Кадыйрова.

Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Рәмис Мөҗипов әйтүенчә, моңарчы гамәлдә булган программада электрон көндәлек һәм билгеләр куяр өчен журнал гына булган.

– Ундүрт елдан бирле ул шактый искерде һәм яңартуны таләп итте, – дигән ул. – Яңа система укучылар һәм аларның әти-әниләре генә түгел, әукытучылар һәм мәктәп администрациясе өчен дә яңа мөмкинлекләр ача. Компьютер версиясеннән тыш, укучылар кесә телефонына – «Я – школьник», әти-әниләр исә «Дневник. Моя школа» кушымталарын урнаштыра ала.

Әйтүләренә караганда, яңа системаның мөмкинлекләре 75 процентка арткан. Былтыр аны тәҗрибә рәвешендә республикадагы берничә мәктәптә сынап та караганнар инде.

– Татарстанда 70 меңнән артык әти-әни «Татарстанда электрон белем бирү» системасына кушылды инде, – диде Татарстан дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Хәйруллин. – Яңа программага керә алмаучыларга борчылырга урын юк. Моны 22 гыйнвардан соң, мәктәпләрдә штатлы расписание төзелеп беткәч һәм оештыру эшләренә бәйле мәсьәләләр хәл ителгәч тә эшләргә мөмкин булачак. Шунысын да искәртик: укыту-тәрбия эшләренә бернинди дә зыян килмәде.

Министр әйтүенчә, 22 гыйнвардан соң мәктәпләрдә яңа системага керү өчен логин һәм пароль дә бирә башлаячаклар. Билгеле булганча, электрон программага йә Дәүләт хезмәтләре порталы аша, йә логин һәм пароль ярдәмендә керергә мөмкин. «Яңалыкка ияләнергә генә кирәк. Бирердә барлык шәхси мәгълүмат сакланган. Иң мөһиме – ул укытучыларны хисап тапшыру кебек өстәмә эшләрдән азат итәчәк. Димәк, алар балаларга күбрәк вакыт бирәчәк», – дип тә өстәгән Айрат Хәйруллин.

Ахыры хәерле булсын!

Эльвира ВӘЛИЕВА

08.00 «Җиде энҗе» 6+
09.00, 03.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
10.00 «Кызган казан» 16+
10.30 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.05, 00.40 «Яшьләр тукталышы» 6+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00, 04.35 «Гаилә учагы» 16+
13.30 «Шаян»да Узгареш җиле»
15.30 Композитор Фирзәр Мортазинның иҗат кичәсе 16+
17.15, 21.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит» 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате» 16+
20.00 «Семь дней» 16+
21.50 Т. Миңнуллин. «Әзләдем, бәгърем, сине». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.05 «Манзара» 16+
02.45 «Шаян хәлләр» 16+
03.15 «Әдәби хәзинә» 6+
05.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10, 00.50 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Жизнь своих» 12+
11.05 «Повара на колесах» 12+
12.15 «НЕ СТРЕЛЯЙТЕ В БЕЛЫХ ЛЕБЕДЕЙ» 16+
15.10 Фигурное катание. Чемпионат России по прыжкам 2024
18.00 Вечерние новости
19.00 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
23.00 «КОНТЕЙНЕР» 16+

РОССИЯ 1

06.10, 01.30 «СВАДЬБЫ НЕ БУДЕТ» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома»
09.25 «Утренняя почта»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 17.00 Вести
12.00 «Большие перемены»
13.00 «ЛЮБИТЬ ВРАГА» 12+
17.50 «Песни от всей души» 12+
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 21.15 Смешанные единоборства. UFC
09.00, 09.30, 14.10, 18.55, 03.55 Новости 0+
09.05, 11.55, 14.15, 19.00, 22.15, 00.45 Все на Матч!
09.35, 12.35 Биатлон. Альфа-Банк Кубок России. Масс-старт
10.55 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
11.25 «Что за спорт?» 12+
14.55 Футбол. Товарищеский матч. «Зенит» (Россия) – «Динамо» (Узбекистан)
16.55 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. «Зенит-Казань» – «Локомотив»
19.25 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Торпедо» – «Новая генерация»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии
01.50 Мини-футбол. Чемпионат России. ПАРИ-Суперлига. «Тюмень» – «Сиб-Транзит» 0+
03.40 «Вы это видели» 12+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА» – «Енисей» 6+

НТВ

04.40 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» 16+
06.30 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
12.00 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Человек в праве» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели»
20.20 «САРМАТ» 16+
00.00 «Звезды сошлись» 16+
01.35 «Основано на реальных событиях» 16+
03.05 «ЖЕНА ПОЛИЦЕЙСКОГО» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «Предсказания: 2024» 16+
07.20 «ГДЕ ЖИВЁТ НАДЕЖДА?» 16+
11.25 «ПРОВИНЦИАЛКА» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
00.30 «ТОТ, КТО РЯДОМ» 16+
03.45 «НЕ В ДЕНЬГАХ СЧАСТЬЕ 2» 16+

ЗВЕЗДА

07.25 «ШЕЛ ЧЕТВЕРТЫЙ ГОД ВОЙНЫ...» 12+
09.00 «Новости недели» 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.40 «Скрытые угрозы» 16+
11.30 «Код доступа» 12+
12.20 «Легенды армии» 12+
13.10 «Специальный репортаж» 16+
13.50 «Легенды госбезопасности» 16+
14.40 «Без права на ошибку» 16+
18.00 Главное 16+
19.45 «Легенды советского сыска» 16+
23.00 «Фетисов» 12+
23.45 «ИЗ ЖИЗНИ НАЧАЛЬНИКА УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА» 12+
01.25 «ДОБРОВОЛЬЦЫ» 12+
03.00 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
04.15 «ВНИМАНИЕ! ВСЕМ ПОСТАМ...» 12+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә мөһим өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Республика мәгълүмат-исәпләү үзәге» акционер җәмгыяте мәгълүмат технологияләре һәм хуҗалык эшчәнлеге бүлегенең гомуми тәэминат төркеме белгече **Сабиров** Наил Мөхәммәтҗан улы, Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Ветераннар (пенсионерлар) төбәк иҗтимагый оешмасы «Ветераннар (пенсионерлар) оешмасы советы» иҗтимагый оешмасының Сарман район оешмасы әгъзасы **Салихов** Мирсаев Миргаҗәм улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм халыкның санитария-эпидемиология ягыннан иминлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертүе өчен «Казан шәһәренең дезинфекция станциясе» муниципаль бюджет учреждениесенең тулы дезинфекция уздыру һәм санитар эшкәртү бүлеге табибы-эпидемиологы ярдәмчесе **Галәүтдинова** Рәисә Әхәт кызы, муниципаль милеккә идарә итүне камилләштерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе рәисе **Галәүтдинов** Ренат Габделхәмит улы, республиканың урман хуҗалыгын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасары **Гомәров** Рәис Кәлимулла улы, һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – икътисад һәм финанслар буенча директоры **Сафиуллин** Илшат Илдус улы, «Инвестнефтехим» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директорының мәгълүмати проектлар белән эшләү буенча урынбасары **Семин** Максим Владимирович, мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының кадрлар сәясәте бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Шәяхмәтова** Гөлзадә Мөдәррис кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы» Берлеге рәисе **Агиев** Шамил Рәхим улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе башлыгы, полиция подполковнигы **Фәсхетдинов** Айдар Назиф улына **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, элекке ТАССР Министрлар Советы Эшләр идарәчесе урынбасары
СӘЙФУЛЛИН
Сәлим Гәрәй улының
вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Ләйсән САФИНА

ЯРАМАГАН ТАГЫ БАЛА-ЧАГАГА?

ИСЕМ САЙЛАГАНДА НӘРСӘГӘ ИГЪТИБАР ИТӘРГӘ?

Хәзерге заманча яңгырашлы ят исемнәргә күнегеп беттек бугай инде. Яшь әти-әниләр яңа туган балаларына нинди генә исемнәр кушмый. Яңгырашы матур дип, мәгънәсе аңлаешсыз, хәтта берникадәр сәер исемнәр сайлау модага кереп бара. «ВТ» хәбәрчесе «заманчалык»ның сәбәпләрен ачыкларга тырышты.

Исем генә димә

Дөньяда кеше исемнәренең күптөрлелеге буенча татарлар беренче урында тора. Бездә 25 меңнән артык исем бар икән. Һәркайсының – үз мәгънәсе. Бүген нинди исемнәр модада? Ни өчен әти-әни баласына гадәти булмаган исем кушып, «мөгез чыгарырга» ярата? Белгечләр фикеренчә, бу күренеш ата-аналарның башкалардан аерылып тору теләгенә бәйле.

– Балага гадәти булмаган исем бирү омтылышы еш кына аерылып тору һәм игътибар җәлеп итү теләге белән аңлатыла. Бу вакытта әти-әни бала турында түгел, ә үзләре турында уйлый, – ди психолог Надежда Мәхмүтова. – Балага үзенчәлекле исем кушуның уңай яклары да бар. Сирәк исемле балалар еш кына үз-үзләрен тотышы, мөмкинлекләре, иҗади сәләте белән аерылалар.

Җәмгыятьтә исем кешенең холкына, язмышына тәэсир итә дигән ышаныч яши. Надежда Мәхмүтова да исем кеше тормышына йогынты ясый дигән фикердә.

– Балага исем сайлаганда, аның мәгънәсенә, килеп чыгышына игътибар итәргә кирәк. Әмма кайбер әти-әниләр моңа бик җиңел карый. Гайре табигый исем кушып, кешене шаккатырырга тели. Модага иярергә кирәкми. Мода тенденцияләре тиз уза, ә балага гомер буе шул исем белән яшисе. Шуны уйлап эш итәргә кирәк. Начар мәгънәле исем баланың психикасы бозылуга, ямьсез холыклы булуына, авыруларга ансат бирешүенә сәбәп булырга мөмкин, – ди ул.

2024 елда нинди исемнәр популяр булачак? Бу хакта маркетолог, кеше исеменең цифрлы криминалистик методологиясе авторы Зөфәр Таһиров сөйләгән. Аның фикеренчә, балалар исемнәренең билгеле бер елга популярлыгын фаразлау кыен, чөнки мода тенденцияләре һәрвакыт үзгәреп тора. Әмма хәзерге вакытта популяр булган һәм быел актуаль булып калачак кайбер исемнәр бар. Татар исемнәре арасында болар – Айгөл, Айдар, Айнур, Айшат, Әлия, Дамир, Эльмира, Фәрит һәм Рөстәм.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Шок хәлендә калдылар»

Популяр блогер Алия Рәҗәпова (Аляска) күптән түгел әни булды. Ире Марат белән улларына Тим дип исем кушканнар.

– Малай буласын белгәч тә, шулай дип атарга булдык. Дөрес, мулла икенче мөселман исеме кушты. Тик барлык кеше өчен ул Тим булачак, бу аның тулы исеме, – дип язган блогер социаль челтәрләрдә. – Запаста тагын ике исем бар иде: Дамир һәм Мартин. Дамир – чын татар исеме. Минем өчен бу – якты, кадерле нәрсә. Борынгы исем булса да, ул миңа бик заманча кебек тоела. Ләкин минем әтиемнең бабасы Дамир булган, шуңа кабатланырга теләмәдек. Язмышларның кабатлану ихтималы да бар, дип әйтәләр.

Чаллыдан Лилия һәм Рәсим Ибраһимовлар да сабыйларына үзенчәлекле исем сайлаган. Алар беренче кызларына Луна (басым у хәрефенә ясала) дип кушкан. Луна хатын-кыз исеме латинчадан «балкыш», «ай яктысы» дигәнне аңлата.

– Кызыбызга матур һәм гадәти булмаган исем теләдек. Сирәк булсын һәм башкалардан аерылып торсын, дидек. Очраклы гына Луна исеменә тап булдык һәм ул шунда ук күңелебезгә үтеп керде. Озак уйладык, әмма кызыбызны башка исем белән күз алдына китерә алмадык. Туганнар исемне бала тудыру йортыннан чыкканда гына белде. Бераз гаҗәпләнделәр, ләкин каршы килмәделәр, – ди 26 яшьлек Лилия.

Танылган алып баручы, җырчы Ләйсән Таишеваның да балаларының исемнәре гадәти түгел.

– Улым Роланга исемне мин уйлап таптым. Ирем – рус, үзем татар булгач, интернациональ исем теләдек. Интернеттан эзләп, китаплар укып, Ролан исемен күрдем дә гашыйк булдым. Башта малайга исемне ирем уйлый, кызга мин табам дип уйлаган идек. Тик аның вариантларына риза булмадым, – дип сөйли Ләйсән. – Ролан исеме туган җир, дан, гаделлек дигәнне аңлата. Мәгънәсе бик көчле, яңгырашы да матур. Кызыбыз Эммага исемне Ролан сайлады. Башта Алиса дип кушарга теләдек. Татар телендә дә матур, русча да яңгырый бит. Әмма улыбыз сайлаганны куштык.

Бу – кызык!

Берничә ел элек Америка психологы Джин Твендж тикшеренү уздырган. Үз исеменнән канәгать булмаган кешеләрнең, башкалар белән чагыштырганда, төрле психик комплексларга күбрәк бирешүен һәм үз-үзләренә бик ышанмауларын ачыклаган. Нәтиҗә гади: әгәр кеше үз исемен яратмаса, ул үзен дә яратмый.

Яңа исем – яңа тормыш?

Тормыш булгач, бар да була. Тора-бара исеменнән канәгать булмыйча, аны үзгәртүчеләр дә бар. Исем алыштыру – җисем алыштырумы? «Болгар радиосы»ның яңалыклар бүлеге редакторы Камилә Шәһәбиевадан әнә шул хакта сораштык.

– 2017 ел. «ТНВ» телерадиокомпаниясенә килеп, радиода яңалыклар бүлегендә эшли башлаган чагым. Дәүләт Советына эш буенча беренче баруым иде. Лифтка кердем, каршымда ак сакаллы бабай тора. «Исемең ничек?» – дип сорады. «Гөлнара», – дим. «Беләсеңме, сиңа бу исем бармый, алыштырырга кирәк», – диде. Берникадәр вакыттан соң исемемне чын-чынлап алыштырасым килә башлады. Моның өчен кеше эзли башладым. Ул вакытта радиода дини тапшырулар алып барган Дилбәр Фәиз бер номер табып бирде. «Хәтер» мәчете имамы Харис хәзрәт Салихҗан янына барырга киңәш итте. Барсам, каршымда Дәүләт Советында очраган ак сакаллы бабай басып тора! Ходай шулай кушкандыр инде, үзе әйтте, үзе алыштырды. Яңа исем зур үзгәрешләр алып килде, дип әйтә алмыйм. Шөкер, тормышымнан зарланмыйм. Исем белән үземне камилләштерергә теләдем, – ди Камилә Шәһәбиева.

2023 елда Татарстанда яңа туган балалар арасында иң популяр исемнәр

Кызларга кушылган иң популяр 5 исем арасына Әминә (408), София (309), Ева (308), Ясминә (287) һәм Амелия (286) кергән. Ир-ат исемнәре арасында Әмир (397), Тимур (307), Марк (276), Матвей (269), Кәрим (265) исемнәре популяр.

2023 елда Татарстанда яңа туган балалар арасындагы иң сирәк исемнәр

Кызлар арасында – Алеся, Мухлисахон, Илида, Люция, Дилара-Бирсен. Малайлар – Бехруз, Абдулбатин, Мудасир, Вилен, Гор.

Фикер

Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре Ләйлә ДӘҮЛӘТШИНА:

– Миңа калса, хәзер үзебезнең чын татар исемнәрен кушу популярлаша бара. 1990 нчы еллар ахыры, XXI гасыр башында авылларда төрки нигезле исемнәр кушу, гарәп теленнән кергән, йола исемнәре күп кушалар иде. Кемнәрдер аларны хәзер дә үз итә. Модага ияреп, баласына заманча исем сайлаучылар да бар. Андыйлар һәрвакыт булган. Соңгы вакытта Европа алынмалары, неологизмнар, чит телләрдән кергән исемнәр күбәеп китте. Бер көнлек исемнәргә кызыгырга кирәкми. Традицион татар исемнәренә йөз тотсак, дөресрәк булыр. Алар барысы да тупланган. Гомәр Саттаровның «Татар исемнәре сүзлеге»н ачып, һичшиксез, күңелгә ятышлысын табарга була. Исем бит ул хәреф кенә түгел. Аны баланың киләчәген уйлап кушарга кирәк. Әти-әниләрнең шул сүзлектән исемнәрнең мәгънәсе белән танышуын теләр идем. Казанның ЗАГС идарәсе белән берлектә электрон белешмә дә әзерләдек. Анда татар исемнәренең әйтелеше дә, дөрес язылышы да, безгә яки ЗАГСка мөрәҗәгать итеп, карау һәм сайлау мөмкинлеге дә бар.

Нихәлләрдә ятасыз?

Сукмакларны кар каплап китмәдеме? Суыкларны ничек җиңәсез? Мал-туарыгыз исән-саумы? Йомырка бәяләре күтәрелгәндә, тавыклар турында да сорашмыйча булмый. Ничек кәефең, авыл?

Альбина ӘХМӘТШИНА, Ютазы районының Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы:
– Хәзерге вакытта үзара салым акчасы җыябыз, халык һәм мал, кош-кортларның санын алабыз. Җирлектә 1040 кеше пропискада исәпләнә. Ике авылда бөтенләй кеше яшәми. Шулай да зиратларны карап тотабыз. Былтыр 6 бала туса, 18 кеше вафат булды.

Озаклап ял иткәннән соң, яңа эшкә керештек бит әле. Терлек, кош-кортларның баш санын алу икенче көн дәвам итә. Әлегә 40ка якын сыер, 2 кәҗә, 100дән артык тавык теркәлгән. Гыйнвар ахырына кадәр исәпләп бетерергә кирәк. Песи, этләрне дә санарга кушалар хәтта. Әлегә маэмайлар саны – биш. Йомыркага кытлык юк дисезме? Авылдагы ике кибеттә дә бар ул. Шәхси хуҗалыктагылар да шунда куеп сата. Бер данәсе – 17 сум. Бу вазгыятьтән соң тавыкларны күбрәк асрый башларлар, бәлкем.

Үзара салымны 600 сум дип билгеләдек. Арттырып булмый, менә шуны җыя алсаң да, бик әйбәт. Авылда гомер буе яшәүчеләр аңлый, ә менә күченеп килүче яшьләрнең әллә ни исе китми. Әллә үзара салым турында белмиләрме шунда. Быел юлларга таш җәячәкбез. Гадәттә бу акчага ут-юл, зиратларны тәртиптә тотабыз.

Сания ҖӘЛӘЛИЕВА (Биектау районының Матмыр авылы):
– Кыш көне кечкенә авылларның борчуы бер генә: юлларны ачсыннар, гел чистартып торсыннар иде. Юлсыз интегәбез бит кайчак. Барлыгы 14 йорт бар. Җиде йортка – 12 кеше, калганнары кайтып-китеп йөри. Күбебез – әби-бабайлар. Миңа – 77 яшь. Ирем хастаханәдә дәвалана. Юл булмагач, биш көн авылдан чыга алмады. Зарланып әйтүем дә түгел. Янгын чыга калса, кеше чирләсә, нишләргә? Машиналар керә алмый. Яшь чагыбыз түгел, карга чумып барып булмый. Әлегә юллар чиста үзе. Ә кар яуса?! Кемгә шалтыратырга дип аптырап тора идем әле. Рәхмәт яугыры, бик урынлы шалтыраттың. Безне ишетерләр дип ышанам.

Флера ШӘЙМАРДАНОВА (Зәй районының Әхмәт авылы):
– Авылда кар бик күп ява, көрәп бетерерлек түгел. Көн саен көрәп торабыз. Юлларны чистартып торалар. Бернинди зарыбыз да юк. Салкын, әлбәттә. Сәламәтлек какшап киткәч, балыкка да барган юк әле. Шуңа күрә өйдә генә җылынып утырабыз.

КЕМ КӨРӘГӘН БУ КАРНЫ?

Буа

Тимурчылар юк бит инде дисезме? Бар алар, исеме генә үзгәрде: әлеге хәрәкәттә катнашучыларны хәзер яшь юнармиячеләр дип йөртәләр. Кызыл берет кигән егет-кызлар ялгыз яшәүче өлкәннәргә төрле эшләрдә булыша. Шөкер, авылларда игелекле гамәлләр кылып яшәүчеләр бар әле.

Буа районының Кайбыч авыл җирлеге башлыгы Сиринә Нуретдинова үзе дә аптырап тормый. Кар күп яуса, көрәген тотып, үз урамында яшәүче әбиләрнең карын көрәшергә китә.

– Безнең урамда өлкәннәр күп яши. Берничәсен шефлыкка алдык. Кибеттән ашамлыгын, даруханәдән даруын алып кайтам, мунчага чакырабыз. Буран котырган чаклар да була. Үзебезнең капка төбен көрибез дә улым белән әбиләр янына китәбез. Алар бөтенләй үк ялгыз түгел анысы. Балалары бар, тик читтә яшиләр. Без инде өйләреннән чыгарга аптырап ятмасыннар дип тырышабыз. Күрше егет тә булышкалый. Кайбер чакта әбиләргә әйтеп тә тормыйбыз. Шулай күнегелгән инде. Тик шаяртып, «капка төбең чиста, эсвиданиягә бара аласың» дип шалтыраткалыйм, – ди Сиринә Нуретдинова.

Аның әйтүенчә, мәктәп укучылары да өлкәннәрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләрен ярдәмсез калдырмый. Килеп, бар эшләрен ялт иттереп китәләр.

АЧЫК БУЛСЫН ЮЛ

Нурлат

Кыш җитсә, авылда тракторчыдан да кадерлерәк кеше юк. Кадерле булмаска, кардан арындыручы, авыл белән шәһәрне бәйләүче бит ул. Һәрхәлдә, Нурлат районының Бикүле авылы тракторчысы 53 яшьлек Марат Гатин әнә шундыйлардан. Үзенең дә башында бер генә уй: юллар ачык булсын! Ә трактор 2017 елда республикада беренчеләрдән булып үзара салым акчасына алынган.

Марат Гатин колхоз таралганчы, 20 ел комбайнчы булып эшләгән. Авыл советы техникасына утыруына 4 ел икән. Трактор булмаса, эш харап. Иртәнге сәгать 4–5тә үк рульдә инде ул. Эше җаваплы: урамдагы чисталык өчен җавап бирәсе. Авылдашлар фикере – иң зур бәя. Бикүледә генә көнгә 25 чакрым әйләнә ул. Бу әле бер якка гына, юлның икенче ягын да эттерергә кирәк.

– Декабрьдә кар күп яуды. Шуңа күрә бер көн дә туктап тормадым. Вакытында чистартмасаң, дөнья карга күмелә, техниканың көче җитми. Шуңа күрә вакыт белән исәпләшмим: төнге 12дә урам әйләнгән чаклар да булгалый. Трактор булмаган чакта, авылдан чыга алмыйча батып ята идек. Авылда эш юк, шуңа күрә күпчелек кеше Нурлатка барып

эшли. Таксистлар да сәгать 5тә эшкә кузгала, – ди тракторчы. – Без инде механизатор эшенә күнектек. Яшьләр түзмәс дип уйлыйм, аларга акчалы эш кирәк. Өстәмә табыш та бар. Кибет тотабыз, казлар, күркә, чебешләр асрыйбыз.

БӘКЕЛЕ АРБАШ



Балтач

Әйдә, киттек бәкегә! Балтач районының Арбаш авылында яшәүче егермедән артык егет кышын бергәләшеп су коенырга йөри. Иң өлкәнене – 64. Җиде ел инде шулай. Бу салкыннарда туңып, тәмам чирләп бетмиләрме?

Арбаш үзе артык зур авыл түгел: йөздән артык йорты бар. Әмма соңгы вакытта ул башкаларны да үзенә җәлеп итүче бәкесе һәм нык бәдәнле, көчле рухлы егетләре белән мактана ала. Ашыкмагыз: алар суга керә дип, сезгә бәкегә чумарга кушмыйбыз. Һәр нәрсәнең тәртибе бар. Иң мөһиме – курыкмаска!

Инешне бөяп, коену урыны ясаганнар. Башта бозны пычкы белән кисеп, шунда иркенләп йөзгән алар. Хәзер бәкедә атнага ике тапкыр салкын суда коеналар.

Иң беренче булып ферма мөдире Фидаил Хәйруллин су коена башлаган. Бервакытны бәкегә чумучылар хәтта 40тан арткан. Хәзер бераз кимегәннәр. Араларында мәктәптә укучы малайлар да бар.

– Барысын да кызыктан башладык. Сез әйтмешли, башка тай тибүдән. Дүрт малай җыелдык та киттек. Башта читтә куркып карап торганнар хәзер үзләре бездән калышмый. Кан басымым көйләнде, бүсер дә интектерми, аяк туңмый, диләр. Моңа кадәр хатын-кызлар да йөрде. Хәзер күренми башладылар, – ди Фидаил Хәйруллин. – Салкын безне куркытмый. Без аны мунча кереп, бәкегә чумып җиңәбез. Беребез дә авырмый. Башта мунчада ак чыршы белән чабынабыз, аннан бәкегә чумабыз. Мунча кергәндә, каен гөмбәсе (чага) чәе эчәбез. Термоска 2 аш кашыгы вакланган гөмбә, 80 градус җылылыктагы су салып, ун сәгать төнәтергә кирәк. Шуны көн дәвамында эчәргә була. Яман шешне булдырмау, кәефне яхшы тотар өчен файдасы зур.

Егетләр шаккатыра, әмма сез үзегез карагыз инде.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

arskmedia.ru

«КҮРЕШҮНЕ КӨТЕП ЯШӘДЕМ»

АНА, ЮГАЛТЫП, 25 ЕЛДАН СОҢ ТАПКАН УЛЫН ҖИРЛИ...

Арчада яшәүче 88 яшьлек Гайшә апа Якупованың язмышын китап итеп язарлык. Бер йөрәгенә күпме хәсрәт сыйган анның. Башта улы һәлак була, аны җирләргә кайтканда, икенче улы эзсез югала. Бу хәсрәтләрне күтәрә алмыйча, ире үлеп китә. Югалган улы белән 25 елдан соң табышып, тагын ике елдан соң гына очраша алар. Тик бу көннәрдә ананың тагын хәсрәтле чагы. Улы вафат булган. Анның җәсәден Арчага алып кайтачаклар.

Әлегә Гайшә апа кызы Гөлшат тәрбиясендә гомер итә.

Ә бит алар ире Зәки белән шулкадәр матур тормыш итәләр. Ике уллары да Себердә эшләп йөргән чагы. Әле берсе, кайтып, хәл белеп китә, әле икенчесе. Тик кече уллары Ришатның әти-әнисе янына чираттагы кайтуы фаҗига белән тәмамлана. Ул юл һәлакәтенә очрый. Энесенең һәлак булганын ишеткәч, абыйсы Илшат та юлга кузгала. Аны менә кайтып җитәр дип көтәләр дә көтәләр. Ул чакта кәрәзле телефоннар юк, тиз генә хәбәрләшеп булмый. Күпме генә көтсәләр дә, Илшат кайтмый, суга төшкәндәй юкка чыга.

– Ирем бу хәсрәтләрне күтәрә алмады. Бер-бер артлы ике баланы югалт әле. Әле ярый янымда кызым булды. Ачы хәсрәтләрне бергә күтәрдек, – ди Гайшә апа.

Еллар узса да, Гайшә апа Илшатын барыбер көтә. Ана йөрәге ялгышмый, алар 25 елдан соң табыша. Илшат энесен җирләргә кайтканда бәлагә тарый, хәтерен югалта, кайда туганын, әти-әнисе барлыгын – барысын да оныта. Язмыш аны рус милләтеннән булган бер кыз белән таныштыра. Киленнәре интернет аша иренең туганнарын эзли башлый. Ул вакытка Илшатның исеме дә Михаил була инде...

– Бервакыт кызым, шалтыратып, үзләренә чакырды. Ул чакта әле йөгереп йөри торган вакытым. Тиз генә килдем. Кызым миңа бер фото күрсәтә. Илшатымны шундук таныдым. Без аны, яратып, «абый-тәтәй» дип йөртә идек. Дөресрәге, ул энесенә дә, сеңлесенә дә исем биреп, үзенә үзе кушамат уйлап чыгарган иде, – ди Гайшә апа. – Беренче көнне килен белән языштык кына. Икенче көнне кызым аларга скайп көйләргә кушты. Шулай итеп, күрешеп сөйләшә башладык. Алар Хабаровскида яшиләр иде. Ике ел аралашып тордык. Аннары алар безгә кайттылар.

Ул чакта Гайшә апа имгәнгән була. Бер аягы кысылып, мускуллары өзелеп бетә. Икенчесен егылып имгәтә. Улын поездан каршы ала алмый ана. Кайтуларын, өзгәләнеп, өендә генә көтә.

– 2013 ел иде ул. Улым «әнием» дип кайтып керде. Нәкъ малай чагында кебек иде. Күрүгә, йөрәкләрем әллә нишләп китте. Каршы ала алмавыма кыенсындым. Ул чакта мин урында ята идем. Алар мине бастырып та карадылар. Тик озак тора алмадым, яткырдылар. Шунда улым, тезләнеп, аякларымны кочып елады. Рәхәтләнеп елаштык. Тик менә хәзер елый да, көлә дә алмыйм... – ди Гайшә апа.

Алар улының гаиләсе белән 10 ел аралашып яшәргә өлгереп кала. Килен дә Арчаны бик ярата.

– Алар быел май аенда бөтенләйгә Арчага күченәсе иделәр. Былтыр ике ай торып киткәннәр иде. Әле, бәлки, май җиткәнен дә көтмәбез, диделәр. Көтмәделәр инде. Илшатым көтмәде. Декабрьнең 21ендә, ашказаным авыртып китте әле дип, ишеккә барып сөялгән дә шуып кына төшкән. Шунда ук үлә балам. Табиблар, йөрәк, ди. Шул көннән бирле моргта ятты. Инде менә хәзер алар юлда. Шимбә кайтып җитәчәк, ял көнне җирләрбез дип торабыз, – ди Гайшә апа. – Килен, монда калам, ди, икәү яшәячәкбез. Бирде язмыш кирәкне! Кайчак: «Ник миңа гына соң бу?» – дип тә үпкәләп куям. Аннары тынычланам. Аллаһы Тәгалә яраткан кешесенә генә күтәрә алырлык сынау бирермен дигән. Димәк, мин күтәрә алам. Бала хәсрәтеннән ачы хәсрәт юк икән. Ришатымны югалткач, Илшатымны табармын дип яшәү көч бирде. Инде таптым дигәч, тагын югалттым. Үз хәлемне үзем генә беләм. Берәүгә дә мин күргәнне кичерергә язмасын.

ИКЕ БАЛА БЕЛӘН ТОЛ КАЛГАН ГАЗИФӘ:

«БЕЗ БИК БӘХЕТЛЕ ИДЕК!»

Газифә ире белән биш ел гына яшәп кала. Гомеренең иң бәхетле еллары ди ул бу вакытны. Яратып, кияүгә чыга, ике бала таба. Тик бәхете кыска гомерле була. Моннан бер ел элек 37 яшендә ире Марат үлеп китә. Кукмара районының Аш-Бужи авылында гомер итүче 27 яшьлек Газифә Исрафилова бүген ике баласына карап юана. Олысы Марсельгә – 3, Мәликәгә – бер генә яшь.

Газифә Исрафилованың шәхси архивыннан

– Казан дәүләт университетының филология факультетында укыдым. Булачак ирем белән интернет аша таныштык. Мин укып бетергәч, тормыш корып җибәрдек. 2017 ел иде бу. Авылга кайткач, ипи пекарнясына эшкә урнаштым. Ирем дуслары белән түбә ябу бригадасында йөри иде. Бик матур яшәп киттек. Тормышның һәр мизгеленә шатлана бели идек. Бәләкәй генә иске өй сатып алдык. Үз куышыбыз бит дип сөенеп яшәдек. Рәхәт иде ул чаклар, – ди ул.

Газифә Биектау районының Суыксу авылында туып-үсә. Әнисе, сеңлесе, энесе бар.

– Иремне савыгыр дигән идем. Табиблар булмас дигәндә дә аягына баскан кеше иде бит ул. Метастазалар китеп кенә харап булды, – ди Газифә, күз яшьләренә буылып.

Марат 2020 елда авырып китә. Кинәт ябыга башлый. Хәле юклыктан зарлана. Кукмара табиблары Казанга җибәрә. Ашказаны белән уникеилле эчәк арасына шеш үскәнен шунда беләләр. Табиблар, соң килгәнсез дип, терелүгә өмет бирмәсәләр дә, дәваларга алыналар, 7 сәгатькә сузылган катлаулы операция дә була.

– Ирем үзендә яман чир икәнне башта белмәде дә. Тереләм, диде. Яшәү теләге зур иде. Дөрестән дә, савыгып китте. Ай саен тиешле анализлар тапшыра башлады. Бар да яхшы иде. Ел ахырына инде беренче балабыз туды. Ул чакта Маратның сөенүләрен күрсәгез! Кош тоткандай очып кына йөрде, – ди Газифә. – Улыбызга ике яшь дигәндә кызыбыз туды. Шул вакытларда Маратның тәне саргаеп киткәндәй булды. Ул яңадан табибларга күренде. Бу юлы анализлар сөендермәде. Бавырына метастазалар киткән иде. Казан табиблары да, Кукмаранықылар да иремнең көнен төшермәде. Аларга шуның өчен мең рәхмәт. Миңа озак яшисе калмаганын әйтсәләр дә, үзенә берни сиздермәделәр. Бавырына операция дә ясап карадылар. Тик шешнең бик катлаулы җирдә урнашуын, алып бетерә алмауларын әйттеләр. Ирем химия терапиясе ала башлады. Янәсе, җиңәбез! Инде хәле авырайгач кына, үзенә авыруы хакында әйтергә туры килде. Анда да өметен өзмәдем әле...

Көчле рухлы була Марат. Сабыйлар хакына дип яшәргә омтыла. Бер дә зарланмый, сукранмый. Үләренә бер көн кала ике тәлинкә аш ашап куя. Иртәгәсен исә бөтенләй сөйләшми дә, ятып кына тора. 2022 елның 2 августында гаилә Маратсыз кала.

– Миңа ул чакта да, хәзер дә бик авыр. Әле ярый иремнең әти-әнисе, туганнары, дуслары ташламады. Үземнекеләр дә гел янәшә булдылар. Югалту ачысына түзә алмыйча, күп еладым, кая барып бәрелергә белмичә тилмердем. Кечкенә ике балама карап, яшәр өчен көч таба алдым , – ди Газифә. – Маратсыз бик авыр. Әмма язмышлардан узып буламы соң! Мин күрәсен кеше күрми, дим. Әлегә мин декрет ялында. Җәйгә кызымны бакчага урнаштырып, эшкә чыгармын дип торам. Бирешергә ярамый миңа. Ике баламны аякка бастырасым бар. Маратым күкләрдән карап торадыр кебек.

Газифәгә авылдашлары ярдәм итеп тора икән. Ялгызына гына ике баланы тәрбияләү җиңел түгел. Күңеле кушканнар Газифә Исрафилова исемендәге Саклык банкы картасына акча күчерә ала. Карта 89393826991 телефон номерына беркетелгән.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

РЕЗЕДӘ СӘЛАХОВА:
«АКЫЛЛЫ, СҮЗЕН БӘРЕП ӘЙТӘ ТОРГАН ТАМАШАЧЫГА КЫЗЫГАМ»

Татар Медеясе – Мәдинә, Заһидә Тинчурина, Сәйдәш мәхәббәте Гөләндәм туташ, беркатлы асрау, акылга сай кыз, берсен-берсе кабатламаган тагын әллә никадәр роль иясе ул Резедә СӘЛАХОВА. Моңа остаз һәм оста алып баручы булуын, татарча мультфильмнарда күп кенә персонажларының аның тавышы белән сөйләвен, «Китап» радиосында әсәрләр укуын да өстәргә кирәк. Бүгенге театрның һәм актерның халәте – әңгәмәбез әнә шул хакта булды.

:: Резедә, яңа елның беренче тәэсирләре нинди?

– Мин бәйрәмнәрне көтеп ала торган кеше түгел. Гомумән, нәрсәдер көтеп яшәмим. Аның һөнәргә бәйле ягы да бардыр инде. Бәйрәм җитте исә, халык ял итә, ә без – ял иттерүчеләр рәтендә. Шуңа күрә тыныч кына озатып җибәрдек, тыныч кына яңа елга аяк бастык.

Узган елда югалтулар да булды. Әниләр, мәсәлән, алты бертуган иделәр, хәзер инде дүртәү генә калдылар. Театр дөньясы да югалтулар кичерде. Уңышларны барласак, театрда Ркаил Зәйдулла әсәре буенча «Ашина» спектакле чыкты, аны тәнкыйтьчеләр дә җылы кабул итте, тамашачылар да. Илсур Казакбаев безнең театрда беренче тапкыр спектакль куйды һәм бик эзләнә торган режиссер булып күңелдә калды.

> Соңгы елларда яшь режиссерлар арасында бу – бик сирәк очрый торган күренеш. Ни кызганыч, хәзер тышкы кабыкка гына кызыгалар, эчтәлеккә бик игътибар итмиләр, эчтәлекне ачу белән шөгыльләнмиләр дисәк тә, әллә ни хата булмас. Матур ут, мишура, оннар, ялтыравыклар белән генә яхшы спектакль чыгарып булмый шул.

Ә «Ашина»га алынгач, без сугыш, репрессияләр турында өстәмә әдәбият та укыдык, фильмнар карадык, бу фаҗига үз нәселләребездә нинди чагылыш тапкан – шуларны өйрәнеп, бер-беребез белән уртаклаштык. Эзләнү, ачышлар белән башланып киткән әсәрне бик яратып чыгардык һәм бик яратып уйныйбыз. Гәрчә җиңел спектакль булмаса да. «Ашина»да вакыйгалар күбесенчә монологлар аша ачыла. Ә озын монологларда тамашачы игътибарын тотып тору бик зур хезмәт таләп итә. Минем өчен узган ел шушы спектакль һәм Нурихан Фәттах әсәре буенча төшерелгән «Кырык дүртнең май аенда» фильмы (режиссеры – Александр Далматов) белән кадерле.

Былтыр Әмирхан Еники әсәрләре буенча «823 нче километр» дигән фильм да чыкты. Анда мин «Матурлык» әсәреннән ана ролен башкардым. Шушы әсәрне укыганда ук: «Их, ана ролен башкарсаң иде», – дип уйлаган идем, хыялым чынга ашты.

> Беркайчан да «голубая героиня»ларга кызыкмадым, миңа характерлы, ямьсез, шадра, кәкре, бөкре образлар күбрәк ошый. Авыррак булганга һәм төсмерләр өстәү мөмкинлеге биргәнгәдер, мөгаен.

:: Соңгы вакытта рольләрең азайды кебек.

– Бу – нормаль күренеш. Театрга яшьләр килә, буыннар алмашы бара. Без инде урта буын рольләрен, алары булмаса, әбиләр ролен биргәнне көтеп утыра торган вакытка җитеп киләбез. Хәер, холкым буенча мин биргәнне көтеп утыра торган кеше түгел. Эш күп, театрдан тыш та эшләр шактый. Хәзер инде «Кырык дүртнең май аенда» фильмының премьерасын көтәм. Быел мартта экраннарда күрербез дип өметләнәм. Анда төп роль – Хәмдияне уйнадым. Бу повесть катлаулы, заманында аның авторына хәтта, азагын үзгәрткән очракта гына бастыра алабыз, дигән шарт куйганнар. Һәм аның финалы ике төрле. Фильмның сценарий авторлары Александр Далматов белән Шамил Фәрхетдинов финалда автор фикереннән бераз гына читкә киткәннәр. Күпкә түгел, әмма аерма бар. Хәмдия – бик катлаулы образ. Ул барысын да кичерә, сугышны да, ачлыкны да, алдануны да, баласын детдомга бирмәс өчен качу, яшеренеп яшәүне дә. Куркып көтүемнең дә сәбәбе шул: Хәмдиянең эчке дөньясын ачып бетерә алдыммы, юкмы дип борчылам.

:: Тәнкыйть һәм мактау: кайсын ничек кабул итәсең?

– Тәнкыйтькә мин әзер. «Ак чәчәкләр» фильмындагы Гөлшаһидә роленнән соң да фикерләр төрле булды. Аның халәты андый түгел иде, чәче кара, күзе зәңгәр түгел иде кебегрәкләрне дә ишетергә туры килде. Мин бик тыныч кабул иттем, профессиональ фикерләрне, әлбәттә, тыңладым. Экранның тәэсире дә, мөмкинлекләре дә бик зур, ул роль, ничек кенә булмасын, мине танытты. Мактауга әллә ни игътибар итмим кебек. Рәхмәт әйтәм дә онытам.

:: Сүз уңаеннан, Тинчурин театры актерларына игътибар җитәрлекме? Әйтик, театр фестивальләрендә, шул ук «Тантана»да сезне күрәләрме?

– «Тантана» кызык булды ул. Театрда «Ди Каприо в юбке» дип йөртә башлаганнар иде инде үземне. Ул, ел саен «Оскар»да номинациягә эләгеп, көтеп алган бүләген ала алмады. Ниһаять, Оскарлы булгач, ресторанда онытып чыгып китә, чөнки инде ул аңа мохтаҗ булмый. Миннән дә, ничә төп ролең белән, ни кызганыч, җиңмәдең, дип көлүчеләр күп булды инде. «Номинациягә эләгеп тә, "Иң яхшы эпизодик роль" белән алдың», – дип тә төрттерделәр. Дөресен әйткәндә, миңа барыбер. Бирсәләр, күңелле, бирмәсәләр дә дөнья үзгәрмәс иде. «Тантана» премиясе лауреаты» дигән исем ул инде бездә болай да бар иде. Аңа Разил Вәлиевнең «Язмышым юллары» әдәби спектакле белән «Иң яхшы ансамбль» номинациясендә лаек булдык. Әлбәттә, «Мәдинә» спектаклендәге төп роль өчен бирсәләр, күңеллерәк булыр иде.

:: Театрдагы соңгы еллардагы эшләреңнән канәгатьме үзең? Кайсы роль иң авыры?

– «Мәдинә» спектаклендәге Мәдинә роле иң авырыдыр, мөгаен. Ак шигырь белән язылганлыктан, тексты да җиңел түгел, персонажы да катлаулы. Башта без үзебез дә бу спектакльгә каршы килдек. «Татар тамашачысына нәрсәгә кирәк бу, ул моны кабул итмәячәк», – дидек. Режиссер һәм пьеса авторы Илгиз Зәйни безнең фикерне тыңлады һәм Артем белән икебезгә: «Сез барыбер төп рольдә уйнаячаксыз», – диде. Башта ук эчке көлмәктән йөрү, үбешү, кочаклашулар булмаячагын әйтте. «Режиссер буларак барысын да уйладым, сез миңа ышаныгыз гына, бергәләп ерып чыгачакбыз без аны», – диде. Әсәрен күптән язган булса да, «Мәдинә» үз сәгатен бик озак көтеп яткан. Үзем дә Мәдинәне башта кабул итмәдем. Репетиция саен ул миңа сеңә барды һәм мин аны аңладым да. Башта нәрсәгә кирәк инде бу азгын хатынны күрсәтү дип карышсам, хәзер аңлыйм: бу – азгын тормышны күрсәтү түгел, шушындый хәлдә калмагыз, Аллаһы Тәгалә сынавын җибәрер, дигән нәсыйхәт дип кабул итәм һәм шундый ният белән сәхнәгә чыгып уйныйм. Уйнаган саен күбрәк яратам.

:: Ә образлар бер-берсен кабатламасын өчен нишләргә кирәк?

– Штампларны кабатлау бик җиңел инде ул, ләкин син артист буларак үсүдән туктыйсың. Режиссер юнәлеш

бирмәсә, аптыравың да, көлүең дә, елавың да, интонацияң дә шул ук булып кала. Рәшит Заһидуллин бу җәһәттән: «Миңа «Кияүләр»дәге Мәйсәрәнең уйнама», – дип гел кисәтә, эзләргә, табарга куша иде. Чөнки ул безнең нәрсәгә сәләтле булуыбызны энәсеннән җебенә кадәр белә, 14 яшьтән үстерде, 12 ел үз канаты астында эшләтте бит. Хәзер теге яки бу чикләрдә син табигый күренәсең икән, режиссерларга шул җитә. Уйналган персонажмы ул синең, табылган образмы – аларны бу кызыксындырмый. Килгән режиссерларны бигрәк тә.

Кабатланмас өчен, артистка юнәлеш бирүче кирәк. Режиссерлар да үз «хотелка»ларын гына тормышка ашыручы түгел, милләт һәм татар театры өчен тырышучы, актерларның үсешен дә кайгыртучы булсыннар иде.

:: Тинчурин театры ул – ...

– ... хәзер инде минем өчен эш урыны гына. Театр дөньясы – тормыш рәвеше.

:: Бүген Тинчурин театры нинди халәттә?

– Бер урында таптанабыз кебек. «Җилкәнсезләр» кебек әйбәт спектакль чыга да, бер адым алга китәбез. Аннары килде-китте комедияләр чыга да, ике адым артка чигенәбез. Ул шулай тиештер бәлки. Кассага эшләргә дә кирәк, тамашачыга нәрсә кирәген дә аңламассың. Ләкин шулай да тамашачының зәвыгын үстерә алырлык спектакльләр күбрәк булсын иде. Әйтик, Уфа гастрольләре шуны күрсәтте: аларда тамашачы бөтенләй башка төрле икән. Анда килде-китте комедияләрне караганнан соң, сәхнә артына кереп: «Җәмәгать, бу безнең зәвыкка туры килми», – дип әйткәннәр. Уфаның акыллы, уйлы, сүзен бәреп әйтә ала торган тамашачысына кызыктым. Ә бит аны, шәп әсәрләр куеп, театр тәрбияләгән. Ә без һаман тамашачыга комедия кирәк дип, кассаны кайгыртабыз дип, һаман да шул «колхозлык»тан китә алмыйбыз.

:: Ике тәкә башы бер казанга сыймый, диләр бит. Ә ике актер башы бер гаиләгә ничек сыеша? Бер һөнәр кешеләре булуның кыенлыклары, рәхәтлекләре нинди?

– Быел никахыбызга 10 ел була. Арабызда ир белән хатын буларак та, актер белән актриса буларак та көнләшү юк. Чөнки мин Артемның ни дәрәҗәдә талантлы икәнен беләм. Ул мине талантлы дип саный. Әгәр инде тәнкыйть сүзләре әйтсәм, үпкәләми. «Нигә мине өйрәтеп утырасың әле?» – дигән нәрсә юк аңарда. Әгәр минем фикер белән ризалашмаса, үз фикерен дәлилли, ахыр чиктә уртак фикергә киләбез. Мин дә аның киңәшләрен кабул итәм. Чөнки Артемда режиссер күзаллавы да бар. Миндә андый сәләт юк, шуңа күрә аннан еш кына киңәш сорыйм. Бу җәһәттән бик күп проектларны эшләгәндә, ул – минем таянычым. Казан театр училищесында актерлык осталыгын укыткач, ул анда спектакльләр дә чыгара. Гаиләдә төрле чак була, андый чакта мин юл куям... дип әйтә алмыйм. Кайвакыт мин, кайчак ул чигенә. Артем ул – гаилә өчен бик рәхәт кеше. Мин фатир өчен күпме түләгәнебезне белмим, күпме кредит түләгәнебезне белмәдем. Счетчик күрсәткечләрен алуның да рәтен белмим. Өлгермәсәм, Артем ашарга да пешерә, идәннәрне сөртеп алырга да авырсынмый. Чөнки алар биш бала үскәннәр, олысы гына апа, калганнары егетләр. Әти-әни аларны төрле хезмәткә өйрәткән.

> Пискуновлар нәселендә бер фраза ошый миңа. Бер-бер хәл килеп чыкса, алар «нәмә инде-е» дип әйтәләр дә җиңел итеп үткәреп җибәрә беләләр. Мин моны керәшеннәргә хас сыйфаттыр дип уйлыйм. Менә шуңа өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле безгә.

:: Керәшен милли костюмын киеп, фотога төшкәч, бик күп тәнкыйть сүзләре яздылар үзеңә.

– Булды андый хәл, төрлесен ишетергә туры килде. Мин аны тыныч кабул иттем. Чөнки без никах белән кавыштык, улыбыз Әскәр – ислам динендә. Баксаң, без очрашып йөргәндә үк, әнием Артемга: «Кызымны никахсыз бирмим, шуңа әзер булмасаң, вакытыгызны әрәм итмәгез», – дип әйткән булган икән. Артем ризалашкан. Никахлашыр чак җиткәч, без аннан тагын бер кат: «Син әзерме моңа?» – дип сорадык. Чөнки бит иман кәлимәсен әйтергә туры киләчәк, бу исә – ислам динен кабул итү. Ул: «Без ике як динне дә хөрмәт итеп үстек һәм мин бу адымга аңлы рәвештә барам», – дип җавап бирде. Артемның әнисе Гөлсинә – татар, әтисе Олег – керәшен. Без диндә үсмәдек, дип әйтә иде ул. Каенатам да алтмышка җиткәч генә чукынган. Минем Артемның фамилиясен алу-алмавым белән дә кызыксынучылар һәм төрттерүчеләр күп. Бигрәк тә Артемга: «Ничек инде син ир-ат буларак хатыныңа фамилияңне бирмәдең?» – дип әйтәләр. Паспорт буенча мин, чыннан да, Сәлахова. Моны да киңәшләшеп эшләдек. Артем: «Сәлахова булып кал, ичмасам фамилиягез бер буынга булса да озынаер», – диде. Без – гаиләдә ике бала, икебез дә – кызлар. Апам инде хәзер башка фамилиядә, әтиемнең дә бертуган абыйлары юк, апалары гына бар. Ни кызганыч, Сәлахова фамилиясе туктала, мин инде аны бер буынга булса да озынайтып, үз фамилиямдә калырга булдым. Артем исә төрттерергә тырышучыларга: «Нишләп әле мин аңа шундый затлы фамилиямне бирим? Татар театры дөньясында бердәнбер Пискунов булып йөрим», – дип шаярып җавап бирә. Мин исә моңа өстәп: «Тәнем белән һәм паспорт буенча Сәлахова булсам да, җаным белән Пискунова мин», – дип җавап бирәм. Артем ул – әтием кебек үк җор телле кеше.

:: Иң зур теләгең?

– Артем белән озак еллар тигезлектә яшәп, улыбыз Әскәргә иптәш алып кайту, гаиләбезне ишәйтү. Ә инде театр дөньясына килгәндә, мин – конфликтларны яратмый торган кеше. Үзем конфликтта катнашмасам да, читтән генә карап торырга мәҗбүр булсам да, эчемдә нидер өзелгән кебек була, курку биләп ала. Шуңа күрә конфликтлар булмасын, дус-тату эшләргә язсын иде, дип телим. Тинчурин театрының үз йөзе, үз тамашачысы бар, аларны югалтмыйча, ишәйтеп, озак еллар канәгатьлек хисе кичереп иҗат итәргә язсын.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Ахыры. Башы 5 гыйнвар санында

РАВИЛ САБЫР (ХИКӘЯ)

ЕГЕРМЕ ҖИДЕ

Шуннан соң шактый гына вакыт йоклап китә алмыйча яттым әле. Әлләниләр уйлап бетердем. Хатын да йокламаган икән:

– Әнкәйгә ничә яшь тулды аңа? – дип сорап куйды.

– Кырык өч, – дидем мин һәм аптырап калдым. Әнкәйгә бүген кырык өч. Димәк, ул мине егерме ике яшендә тапкан, ә әткәй үлгәндә миңа биш яшь иде.

Әнкәй егерме җиде яшендә тол калган.

...Артта авырлы хатының утыргач, басу юлларыннан матайда әллә ни бик элдертеп булмый икән ул. Әкренләп кенә булса да барып җиттек тагын. Авыл башындагы зиратка да күп калмады инде. Мин Түгәрәк урман янында туктадым.

– Курыкмыйсыңмы монда калырга? – дим хатынга.

– Юк.

Инде кузгалып китмәкче булган идем, күзем урман читендә ап-ак буй булып сузылган ромашкаларга төште. Хатын, шул ромашкаларны сыйпагандай итеп, чәчәкләр янәшәсеннән бераз атлады да, туктап, миңа борылып карады. Кызык инде! Әле кичә генә бер шаян кызчык иде, тиздән әни булачак. Ул бер ромашканы өзеп алды да, ирен чите белән генә елмаеп, бер-бер артлы таҗлар өзә башлады. «Ярата, яратмый...»

Мәрхүмгә җыелган букеттагы чәчкәләр саны җөп булырга тиеш икәнен белсәм дә, әткәй өйрәткәнчә егерме җидене җыйдык.

...Күңел сизенү бер нәрсә, ә менә мин зиратта күргәнне... ни дип атарга да белмим. Әткәйнең кабереннән ерак түгел үсеп утырган бер тирәк корыган булган. Бер Алла бәндәсе килеп, шуны кисеп аударган да утынга яраклы өлешләрен җыеп алып киткән. Чабып төшергән ботак-чатакларын каберләр өстенә чәчелгән килеш калдырган. Ничек җир күтәрә шундыйларны?! Әллә, киресенчә, үз куенына аласы килмиме?

Тирәк ботакларын җыеп, зират коймасы янына ташыдым. Әткәй каберенең бер почмагына кычыткан үсеп чыккан иде, аны йолкып ташладым. Урман читеннән җыеп алган егерме җиде ромашканы ташы янына салдым. Аннан соң күңелемнән әткәй белән сөйләшеп алдым.

Бүген, беләсеңме инде, әнкәйнең туган көне, дидем. Кунаклар көтәбез, дидем. Кыш азакларына оныгың да туар инде, Алла боерса. Кыз, кыз туачак, дигән булалар, малай икәнен беләм инде. Синең исемеңә охшатып, бер хәрефне, «с»ны «з»га үзгәртеп, Рәзим кушам, дидем. Исемеңнең мәгънәсен беләсеңдер инде – «зур атлап йөрүче» дигән сүз. Улым бу дөньяда иркенләп яшәсен, бабасына охшасын өчен шундый исем кушам. Моны әле беркемгә дә әйтмәдем, сиңа гына әйтәм, дидем. Югалтып, юксынып ятма, гел шулай килеп йөрермен, тыныч йокла, әткәй, дидем.

Зират капкасыннан килеп чыгуым гына булды, кисәк кенә көчле җил кузгалды. Зиратның карт тирәкләре, шаулаша-шаулаша, башларын минем якка игәндәй тоелды. Бу җил яңгыр болытларын куып алып килмәсен тагын дип, мин Түгәрәк урман янына ашыктым.

Хатын һаман ромашкалар арасында йөри иде. Чәчәкләр, җилдә тирбәлеп, ничектер аңа сырпаланырга, назланырга телиләр кебек иде. Зур гына букет җыйган. Елмаеп, миңа шуны суза:

– Кара әле, ничек матур!

Чәчәкләрне кулыма алуым булды, нәкъ теге чактагы кебек салкынлыктан учым өтелеп пешкәндәй булып китте. Мин, ашыга-ашыга, чәчәкләрне санарга керештем. Йа Хода! Егерме җиде! Тәнемдә ниндидер бер илаһи көч пәйда булып, күз ачып йомганчы үскәннән-үсте һәм үзем дә сизмәстән чәчәкләр бәйләмен күккә, бик югарыга чөеп җибәрдем. Көчле җил ромашкаларны, уйната-уйната, бөтерә-бөтерә, Түгәрәк урман өстеннән очырып алып китте. Хатын аптыраган караш белән аларны озатып калды. Озын керфекләре – әйтерсең лә ромашка таҗлары...

Белдерү

Извещение о проведении собрания по согласованию местоположения границ земельного участка

Кадастровым инженером Осиповым Алексеем Федоровичем (г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524, СНИЛС 047-159-072-63, квалификационный аттестат 16-15-843; реестр кадастровых инженеров № 36006; СРО АКИ «Поволжье» № 1145 протокол № 18/2016 от 22.11.2016 г.) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:180301:135, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, д. Старые Бирюли, ул. Овражная, з/у 10, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Косолапов Александр Николаевич (Российская Федерация, 423232, Республика Татарстан (Татарстан), г. Бугульма, ул. Владимира Ленина, д. 142, кв. 92, тел.: +7 966 2501823 (доверенное лицо)).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, д. Старые Бирюли, ул. Овражная, з/у 10 12 февраля 2024 г. в 10 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524 (предварительно позвонить).

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 12 января 2024 г. по 11 февраля 2024 г. по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524 (предварительно позвонить).

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ:

16:16:180301:134 Российская Федерация, Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, д. Старые Бирюли, ул. Овражная, з/у 10А;

16:16:180301:136 Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, д. Старые Бирюли, ул. Садовая, д. 22.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).



Сканворд җаваплары

Горизонталь: Ася, әрнү, ыс, иза, ымлык, үпкә, ураза, төчкерү, пин, бәс, Әтнә, татлы, рәшә, старшина, МИ, раритет, ас, им, ау, ал, Сәет, Ләис, Урмай, мә, Ла, Нос, Есенин, Искәндәр, аһлы, ЛиАЗ, Зәйни, Николай, АН, Ризат, Нияз.

Вертикаль: аптырау, Иа, Аурус, унтер, Ка, аһәң, абыстай, НЛ, Фәйрүзә, тел, Адымнар, Пассат, Инин, Янтык, сәерлек, мәтрүшкә, олан, ил, Елена, ТИ, сызыкча, Натан, ясак, рас, Айваз, Лениз, Рәшидә, утә, индий, мисо, Хәким, Сони.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Бәйрәмнән соң

Яңа елны чиста биттән яши башлыйм, дип уйлап кына куясың, берәрсе бәйрәм корпоративыннан фотолар җибәрә.

Быел һәр адымыңны социаль челтәрдән күзәтеп бардык. Ел нәтиҗәләре язып тормасаң да була.

Һәр Яңа елны безнең дусларда бер үк традиция: бәйрәмнән соң беребезнең дә акчасы калмый.

31 декабрь көндез төркемдә языша-лар: «Берәрегездә ашарга юкмы? Безнең бөтен ризык Яңа ел өчен».

Быелгы 1 гыйнвар яңа көн, яңа атна, яңа ай һәм яңа ел булган икән бит! Яңа тормыш башларга менә дигән форсат! Ник алдан әйтмәдегез?

«Ирония судьбы»ны Ипполит күзлегеннән карасагыз, бүтән карыйсыгыз килмәс.

Дөрес туклана гына башлыйсың, Яңа ел, туган көн, 8 Март яки отпуск килеп җитә.

– Кадерлем, Яңа елда иске әйберләрдән арынырга кушалар...
– Мин китмим!!!

2024 ел туйдыра башлады. Тизрәк 2025 килсен иде инде.

Беләсең килсә...

1 Милиция кайсы елда полициягә әйләнде?
а) 2011;
б) 2012;
в) 2014.

2 Әмирхан Еники әсәре ничек дип атала?
а) «Гүзәллек»;
б) «Матурлык»;
в) «Чибәрлек».

3 Абриколь нәрсә ул?
а) абрикос сорты;
б) бер линзалы бинокль;
в) бильярдта сугу төре.

4 Бу шәһәрнең циркы Казанныкына охшамаган:
а) Краснодар;
б) Грозный;
в) Екатеринбург.

(Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. в); 4. в).)

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының уртак каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13856 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 203

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама булырак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+